КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ
Гомуми тел белеме һәм лингвокультурология кафедрасы

# ӘДӘБИ ТЕКСТКА ФИЛОЛОГИК АНАЛИЗ

***Укыту-методик кулланма***

**Казан**
**2013**

УДК 80/81
ББК 81.2
С 34

Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институты укыту-методик советы карары белән басыла
(14 март, 2013 ел, 6 нчы номерлы беркетмә)

Төзүчеләр:
**Ф.Р. Сибгаева**, филология фәннәре кандидаты, өлкән укытучы
**Д.Х. Хөснетдинов**, филология фәннәре кандидаты, доцент

Фәнни мөхәррир -
**Р.Р. Җамалетдинов**, филология фәннәре докторы, профессор

Рецензент -
1. **И.Җ. Едиханов**, филология фәннәре кандидаты, өлкән укытучы

Сибгаева Ф.Р., Хөснетдинов Д.Х. Әдәби текстка филологик анализ. Югары уку йортлары өчен укыту-методик кулланма. – Казан: Отечество, 2013. – 78 б.

Тәкъдим ителә торган укыту-методик кулланмасы әдәби текстны филологик яктан өйрәнүгә ярдәмлек буларак филология һәм педагогика юнәлешләре буенча белем ала торган югары уку йорты студентларына адреслана. Бу ярдәмлек шулай ук тәрҗемә белеме һәм журналистика белгечлекләре буенча белем алучы студентларга да файдалы булыр дип ышанабыз.

**ISBN 9 78-5-9222-0615-0**

## Эчтәлек

Кереш...............................................................................................4
Әдәби текстны өйрәнүнең кыскача тарихы ....................................5
Хәзерге тел белемендә текст төшенчәсе мәсьәләсе .................. .12
Әдәби текст һәм аңа хас сыйфатларны билгеләү үзенчәлеге .....15
Әдәби текстның төп берәмлекләре ..............................................17
Әдәби текстның төзелеше ...........................................................22
Әдәби текстның тышкы структур үзенчәлеге ..............................23
Әдәби текстның эчке структур үзенчәлеге .................................34
Когезия............................................................................................47
Континуум.......................................................................................50
Тексттагы ретроспекция һәм проспекция .......................... ........51
Әдәби әсәргә филологик анализ ясау тәртибе ...................... .....58
Гамәли дәресләрнең тематикасы ............................................... ..60
Белемнәрне тикшерү өчен тест ................................................ ....63
Реферат темалары ...................................................................... .....68
Зачет өчен якынча сораулык ................................................ .......69
Курсны өйрәнүне оештыруга карата методик күрсәтмәләр........70
Төп әдәбият исемлеге ................................................................ .....72
Өстәмә әдәбият исемлеге .............................................................72

## Кереш

“Әдәби текстка филологик анализ”, “Лингвистик анализ” курслары буенча өйрәнелә торган лингвистик фәннәр арасында үзенчәлекле урын алып тора. Ул сөйләмнең иң зур берәмлеге булган, сөйләмнең төп үзенчәлекләре үзендә чагылыш тапкан берәмлек – текст һәм аның төзелешен өйрәнүгә багышланган.

Курсның төп эчтәлеге әдәби текстны филологик яктан якын килеп өйрәнүгә, филологик яктан анализлауга караган фәнни фикерләр, карашлар чылбырын, нәзари материалны тасвирлаудан гыйбарәт. Курс шулай ук студентларны лингвистик терминология белән эш итәргә өйрәтүне, филологик анализ төрләрен, методларны карауны күз уңында тота. Өйрәнелә торган нәзари материалны ныгыту, студентларның лингвистик фикерләү сәләтен, тел фактларын анализлау осталыкларын үстерү максатыннан гамәли дәресләр дә үткәрү каралган.

“Әдәби текстка филологик анализ», “Лингвистик анализ” курсларыннан укыту-методик кулланмасы татар филологиясе һәм тәрҗемә һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә белем алучы студентлар өчен төзелде. Укыту-методик кулланмада лекция материаллары, гамәли дәрес темалары һәм планнары, тәкъдим ителә торган тел материалын мөстәкыйль үзләштерү өчен темалар, зачет сораулары, белемнәрне тикшерү өчен тест, әдәби әсәргә филологик анализ ясау тәртибе, укытучылар һәм студентлар өчен методик киңәшләр урын алган. Кулланмада нәзари материал карала, аерым сорауларга бәйле өстәмә мәгълүмат бирелә.

## Әдәби текстны өйрәнүнең кыскача тарихы

Текст теориясе хәзерге фән өлкәсендә төрле яклап өйрәнелә. Филологик текстны тикшерү максат һәм өйрәнү чараларына бәйле һәрвакыт үзгәреп тора. Тарихчылар текстны тарихи чыганак буларак тикшерсә, психологлар аны кешенең аң эшчәнлеген ачыклау өчен өйрәнә. Психология, нейролингвистика, когнитив лингвистика, коммуникатив яки прагмалингвистика, компьютер лингвистикасы кебек арадаш юнәлешләр әлеге объектны тәфсилләбрәк өйрәнергә ярдәм итәләр, ләкин текст тулысы белән бары тик филологиядә генә ачыла.

1981 елда Р.А. де Бегранд һәм В.Дресслер белән берлектә “Текст лингвистикасына кереш” дип аталган беренче хезмәт басыла. Әлеге монографиядә төп игътибар текстуальлек төшенчәсенә, аның сыйфат һәм категорияләренә бирелә. Авторлар, текст лингвистикасы үсешенә кыскача күзәтү ясаганнан соң, текстуальлекнең җиде шартын аерып күрсәтәләр: 1) когезия (бердәмлек); 2) когеренция (бәйләнгәнлек); 3) интенциональлек (билгеле бер максатка юнәлтелү); 4) кабул итү мөмкинлеге; 5) информативлык (мәгълүм күләмдә информациягә ия булу); 6) ситуативлык (контекст эчендә аңлашылу); 7) интертекстуальлек (башка мәгълүматка бәйле булу)˙

20-30 нчы елларда рус тел белемендә Р.О. Якобсон, В.М. Жирмунский, Б.В. Томашевский кебек формализм юнәлеше вәкилләренең хезмәтләрендә текстка җитди игътибар бирелә башлый. Әдәби форманы эчтәлектән аерып өйрәнү тенденцияләре алга таба да Г.О. Винокур, В.В. Виноградов хезмәтләрендә дәвам иттерелә. Г.О. Винокур әдәби әсәр структурасын интерпретация һәм “структураны тәнкыйтьләү” ярдәмендә тикшерергә чакырган булса[1], В.В. Виноградов “әдәби әсәрләрнең телен”, ягъни сөйләмнең композицион төрләрен,

---

[1] Винокур Г.О. Филологические исследования. – М.: Наука, 1990. – С. 15.

семантик һәм стилистик төзелешен өйрәнә торган фән тармагын аерып чыгара[2].

XX гасырның 40-50 нче елларында тел гыйлемендә төп игътибар әдәби сөйләм сүзенең эстетикасын ачыклау, стиль белән матур әдәбиятның статусын билгеләү кебек мәсьәләләргә юнәлтелә. Бу чорда текст структурасы сүз һәм образ төзелеше ягыннан тикшерелә. В. Виноградовның "Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика"[3] китабы чыгу белән әдәби әсәр теле турындагы фән стилистикада аерым тармак буларак өйрәнелә башлый.

60 нчы елларда функциональ стилистиканың үсеш алуы әдәби образның телдә конкрет чагылышы проблемасын торгызып җибәрә[4], шулай ук әдәби әсәрнең синтаксисын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр дә басыла. Бу чорда текст структурасын өйрәнү кирәклеген аеруча әдәбиятчылар ассызыклый башлыйлар. Мәсәлән, Г.А. Гуковский әдәби әсәр структурасын өйрәнү кирәклеге турында: "Стенаны оештырган сүз-кирпечләрне генә түгел, әлеге структураның өлеше булып торган әлеге кирпечләрнең кушылмасын һәм мәгънәсен истә тотырга кирәк," – дип искәртә[5].

XX гасырның 70 нче елларында текстны филологик яктан өйрәнү берничә юнәлештә алып барыла. Беренчедән, В. Виноградов текст структурасын ачыклауны әдәби әсәргә анализ методикасына кертә һәм тикшерүне ике юнәлештән башларга тәкъдим итә:

1) бердәм эстетик әсәр буларак кабул итү (аның иң кечкенә элементлары – аваз белән фонема);

2) автор образы проблемасын үзәккә кую.

---

[2] Виноградов В.В. О теории художественной речи. – М.: Наука, 1971. – С. 23.

[3] Виноградов В.В. Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика. – М.: Наука, 1963. – 245 с.

[4] Кожина М.Н. О специфике художественной и научной речи в аспекте функциональной стилистики. – Пермь, 1966. – 213 с.; Кожина М.Н. К основаниям функциональной стилистики. – Пермь, 1968. – 88 с.

[5] Гуковский Г.А. Изучение литературного произведения в школе: Методико-логические очерки о методике. – Тула: Автограф, 2000. – 223 с.

Бу концепция алга таба да текст системасын һәм аның ни рәвешле оешуын өйрәнүдә зур әһәмияткә ия була.

Филологик текстны өйрәнүнең синтаксик аспекты Г.Я. Солганик[6], С.Г. Ильенко[7], И.И. Ковтунова[8] һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә һәм төрле җыентыкларда[9] чагылыш таба.

2000 нче елларда, ике гасыр чигендә, текст структурасын антропоцентрик, социолингвистик, когнитив, психолингвистик һәм лингвокультурологик юнәлешләрнең интеграциясендә өйрәнү хас. Бу тармакларның барысын да текст эшчәнлегендә ачык чагылган тел иясе белән җәмгыятьне игътибар үзәгенә кую берләштерә. Коммуникатив стилистика исә текст структурасын аның семантик һәм прагматик сыйфатлары белән беррәттән өйрәнүе белән аерылып тора.

Төрки һәм татар лингвистикасында да текст теориясе мөстәкыйль тармак буларак формалашып бара. Текст мәсьәләсенә бәйле фикерләр XX гасыр башларында ук Һ. Максуди, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров кебек галимнәрнең синтаксисны укытуга багышланган хезмәтләрендә урын алган. Текст төшенчәсе турыдан-туры кулланылмаса да, әлеге хезмәтләрдә ким җөмләләрнең бәйләнеше турында әйтелә, теземгә хас мәгънәви һәм структур үзенчәлекләр күрсәтелә.[10]

Совет чорында төрки тел гыйлеме зур үзгәрешләр кичерә, анда төрле яңа юнәлешләр үсеш ала. Бу елларда телләрне һәрьяклап үстерү, тикшерү, өйрәнүгә игътибар арта: күпләп

---

[6] Солганик Г.Я. Синтаксическая стилистика. (Сложное синтаксическое целое): учебное пособие для студентов вузов. — Москва: Высш. шк., 1973. – 212 с.

[7] Ильенко С.Г. Персонализация как важнейшая сторона категории предикативности // Теоретические проблемы синтаксиса индоевропейских языков. – Л.: Наука, – 1975. – С. 85-96.

[8] Ковтунова И.И. Современный русский язык. Порядок слов и актуальное членение предложения.: учебное пособие для пед. институтов. — Москва: Просвещение, 1976. — 239с.

[9] Мәсәлән: Синтаксис текста. – М.: Наука, 1979. – 275 с.

[10] Максудов Һ. Төрки нәхүе. – К., 1910. – Б. 16-20; Ибраһимов Г. Татар нәхүе. –К., 1911. – Б. 23-24; Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы / Җ. Вәлиди. – К., 1919; Алпаров Г. Шәкли нигездә татар теле грамматикасы. – К., 1945. – Б. 121.

дәреслек-кулланмалар басылып чыга башлый, югары фәнни дәрәҗәдә конференцияләр уздырыла.

Төрки тел белемендә текст теориясенә кагылышлы хезмәтләрдән иң беренче чиратта Ә. Дәмирчизадәнең “Азәрбайҗан дилинен үслүбийаты”[11] дигән китабын күрсәтергә кирәк. Югары уку йортлары өчен чыгарылган әлеге хезмәттә, стиль һәм стилистика турында гомуми мәгълүматтан тыш, стилистик фонетика, стилистик лексика һәм стилистик морфология мәсьәләләренә зур урын бирелә. Әзербайҗан галиме В. Юсифли исә үзенең “Хәзерге әзербайҗан матур әдәбиятының стилистик синтаксисы”[12] исемле докторлык диссертациясендә стилистик синтаксисны югары синтаксис дип атый һәм синтаксик категорияләрнең әдәби образ тудырудагы ролен, кулланылыштагы идея-эстетик максатларын өйрәнә. А. Әфәндиеваның “Хәзерге әзербайҗан теленең лексик стилистикасы”[13] хезмәтендә төп игътибар әдәби текстларда омоним, антоним сүзләр, метафора, метонимия, синекдоха, метафорик эпитет кебек тропларның кулланылышына, әсәрнең лексик-стилистик катламнарына юнәлдерелә.

Чуваш галиме Н.А. Андреевның морфологиягә һәм синтаксик стилистикага багышланган хезмәтләрендә[14], А. Кайдаровның “Уйгур теле” дигән хезмәтендә[15] стилистика турындагы махсус бүлекләрдә сөйләм стильләренең төрләре, лексик-синтаксик фигуралар тикшерелә, сүзләрдән һәм морфологик формалардан файдалану ысуллары билгеләнә.

Татар тел гыйлемендә текст турында аерым күзәтүләр Х.Р. Курбатов хезмәтләрендә киң планда тикшерелә башлый. Аерым алганда, татар тел белемендә чит сөйләмнең уртак

---

[11] Дәмирчизадә Ә. Азәрбайҗан дилинен үслүбийаты. – Бакы: Азэр. тэдрис. – Педагожи эдэийаты нэшр., 1962. – 272 б.

[12] Юсифли Ш.В. Стилистический синтаксис современного азербайджанского художественного языка. – Баку, 1973.

[13] Эфендиева Т.А. Лексическая стилистика современного азербайджанского языка.–Баку, 1973.

[14] Андреев Н.А. Чаваш челхин стилистики. Морфология. – Шупашкар, 1964; Андреев Н.А. Чаваш челхин стилистики. Очерксем. Синтаксис. – Шупашкар, 1966.

[15] Кайдаров А. Уйгур тили. – Алматы, 1971.

сөйләм төрен беренче булып Х. Р. Курбатов билгели.[16] Галимнең татар теле стилистикасына багышланган башка хезмәтләрендә дә текст төзелешенә карата кайбер фикерләр әйтелә.[17] Моннан тыш, И.Б. Бәширова, С.Ш. Поварисов, В. Х. Хаков, Ф.С. Сафиуллина, Г.М. Шакирова, М. Шәехов кебек галимнәр дә үзләренең хезмәтләрендә текстка, стилистикага, тел үсешенә, әдәби әсәрне филологик анализлауга бәйле рәвештә текст төшенчәсен читләтеп узмыйлар.

И.Б. Бәширова[18] шигъри һәм прозаик әсәрләрдә сүз белән сурәт ясауның күптөрле алымнарын һәм чараларын барлый, татар әдәбиятының төрле чорларында телне сәнгать чарасы буларак куллану үзенчәлекләрен мәктәп программасындагы әдәби әсәрләр нигезендә бирә.

В.Х. Хаков[19] хезмәтләрендә ХХ йөз башында иҗат ителгән әдәби әсәрләргә һәм публицистик язмаларга лексик-семантик һәм лингвистик-стилистик анализ ясала, хәзерге татар әдәби телен үстерүдә Г.Коләхмәтов, Г.Тукай һәм Ф.Әмирханның рольләре ассызыклана

С.Ш. Поварисов[20] әдәби әсәрләрнең телен өйрәнә, әдәби әсәрнең телен өйрәнгәндә игътибар ителергә тиешле моментларны билгели, сурәтләү чаралары белән бергә грамматик формаларын да тикшерә. Галим төрле жанр әсәрләрендәге лексик берәмлекләрнең күпмәгънәлелеген һәм стилистик характерын ачыклап, эмоциональ-экспрессив сүзләр, гади сөйләм лексикасы, сурәтләү чаралары, автор һәм персонаж

---

[16] Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре / Х.Р. Курбатов. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1956. – 176 б.

[17] Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р. Курбатов. - Казан: Мәгариф, 2002. - 199 б.

[18] Бәширова И.Б. Сәнгатьле чәчмә әсәрләр геле: Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире / И.Б. Бәширова. – Казан: Тат.кит.нәшр., – 1979. – 96 б.; Бәширова И.Б. Сүз белән сурәт ясау (әдәбият укытучысына ярдәмгә) / И.Б. Бәширова. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. – 176 б.

[19] Хаков В.Х. Мәктәптә татар язучысының тел үзенчәлекләрен өйрәнү / В.Х. Хаков. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1984. – 145 б.

[20] Поварисов С. Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү / С.Ш. Поварисов. – К.: Тат. кит. нәшр., 1978. – 217 б.

сөйләме кебек элементларның кулланылышын анализлап, язучыларның индивидуаль стилен билгеләргә мөмкин дип саный.

М.З. Зәкиев текстны “өйрәнү өчен алынган, эчтәлек һәм структур яктан оешкан тоташ сөйләм”[21] дип билгели. Аны макротекст (тулаем текст) белән микротекстка бүлеп, үз хезмәтләрендә төп игътибарны икенче төргә – синтаксик бөтеннәргә юнәлтә.

Текст синтаксисын өйрәнүне беренче планга куеп, галим барлык синтаксик категорияләрнең текст эчендә генә тулысынча ачылып беткәнен раслый. Әлеге категорияләр арасыннан автор хәбәрлек белән модальлекне, ким һәм атау җөмләләрне, җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше белән сүз тәртибе проблемасын, теземнәр һәм чит сөйләм төрләренең кулланылашын аерып күрсәтә.

Ф.С. Сафиуллинаның текст теориясенә багышланган хезмәтләре аерым игътибарга лаек. Галимә тел гыйлемендәге текст теориясе казанышлары нигезендә, татар әсәрләренең текст буларак оешу закончалыкларын, текст берәмлекләре һәм алар арасындагы бәйләнешләр, ретроспекция белән проспекция, континуум һәм интеграция кебек текст категорияләре, әсәр башламнары, уртак сөйләм кулланылышын өйрәнә.

Татар текстын өйрәнү әдәби әсәрләр белән генә чикләнми. В.З. Гарифуллин хезмәтләрендә газетадагы мәгълүмати жанрларның текст буларак оешуы, аларның сөйләм композициясе, модальлеге һәм темпоральлеге тикшерелә, текст төзүдә автор үзенчәлекләренең ни рәвешле чагылганын анализлый[22].

И.М. Низамов исә үзенең хезмәтләрендә сөйләм оештыру өчен кулланылган тел чараларын системага салып өйрәнү омтылышы ясый. Автор адресатка, аралашу ниятенә һәм шартларына карап, сөйләмнең мотивларын, лингвистик һәм экстралингвистик чараларын билгели. Шулар нәтиҗәсендә

---

[21] Поварисов С. Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү / С.Ш. Поварисов. – К.: Тат. кит. нәшр., 1978. – Б. 451.

[22] Гарифуллин В.З. Газета текстының төзелеше / В.З. Гарифуллин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. – 104 б.

галим сөйләмият фәнен тел гыйлемендә мөстәкыйль тармак итеп бүлеп чыгарырга тәкъдим итә, аның предметын, максат-бурычларын һәм берәмлекләрен аерып күрсәтә[23]. Әлеге фикерләрен үстереп һәм баетып, И.М. Низамов үзенең докторлык диссертациясендә татар сөйләменең массакүләм коммуникация системасындагы торышын анализлап чыга.[24]

Татар тел белемендә текст теориясен өйрәнү хәзерге чорда да дәвам итә, әлеге өлкәгә кагылышлы хезмәтләр языла тора. Шулар арасыннан Г.М. Шакированың Ф. С. Сафиуллина җитәкчелегендә Г. Исхакый иҗатын өйрәнүгә багышлап язылган диссертациясен[25] билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге хезмәттә бөек татар классигының әсәрләре өр-яңа ягы белән – текст буларак оешу үзенчәлекләре тарафыннан ачылып китәләр. И.Р. Гальперин методикасына таянып текстның күләм-прагматик ягы тикшерелә. Текстларның синтаксик бөтеннәргә һәм абзацларга бүленү үзенчәлекләрен, аларның текст төзүдә уйнаган роле, башлам һәм бетемнәрнең функцияләре билгеләнелә, язучының иҗат эволюциясе күзәтелә.

Яңа гасыр башында текст теориясенең үсеш-үзгәреше бу чорда булган иҗтимагый-сәяси вакыйгалар белән тыгыз бәйләнгән. Илдәге коммуникация даирәсенең һәм кешеләрнең аралашу активлыгының кискен артуы, массакүләм медиа роленең көчәюе, яңа мәдәниятләр белән тыгыз элемтә урнашуы һәм ныгуы – болар барысы текстларның үзләренә дә, аларны өйрәнү методикасына да көчле йогынты ясый.

Җәмгыятьтә кулланылган һәртөрле текстларны берләштереп тикшергәндә генә халыкның рухи дөньясын ачыкларга һәм әлеге телдә сөйләшүче кешеләрнең аралашу

---

[23] Низамов И.М. Уем тел очында... (Сөйләм һәм массакүләм аралашу) // Беренче кисәк. Татар сөйләменең нигезләре. – К.: Тат. кит. нәшр., 1995. – 287 б.

[24] Низамов И.М. Функционирование и развитие татарской речевой системы в массовой коммуникации: Дис.... доктора филол.наук.10.02.06. – К.:, 1996. – 436 с.

[25] Шакирова Г.М. Гаяз Исхакый әсәрләренең текст буларак оешуы: фил. ф. канд. ... диссертациясе. – Казан, 2009. – 197 б.

компетенциясен билгеләргә мөмкин.[26] Шуңа күрә хәзерге текстларны тикшерүче галимнәр алдында язма әдәби әсәрләрне генә түгел, ә күптөрле телдән һәм язмача, басма һәм электрон формада таралган текстларны да өйрәнү бурычы тора.

## Хәзерге тел белемендә текст төшенчәсе мәсьәләсе

Текст төшенчәсенә билгеләмә бирү әлеге көннәрдә дә бәхәсле мәсьәләләрнең берсе булып кала, чөнки һәрбер телче галим синтаксисның әлеге иң эре берәмлеген төрле яктан өйрәнә һәм яңадан-яңа үзенчәлекләрен ачарга омтыла. Шул сәбәпле хәзерге тел белемендә текстка барлыгы 300ләп төрле билгеләмә бирелгәне табигый[27]. Алар арасында, текст төшенчәсен тар планда карап, аны мәгънәви һәм грамматик яктан бәйләнгән җөмләләр тезмәсенә, ягъни синтаксик бөтенгә генә калдырган[28] һәм киресенчә, киң планда, метафора хәленә китереп, әдәбият, мәдәният һәм җәмгыятьне, тарихны һәм хәтта кешене – барысын да текст дип раслаган галимнәр дә бар[29].

Текстның лингвистик ягын өйрәнеп, беренче тулы билгеләмәне И.Р. Гальперин тәкъдим итә. Галим фикеренчә, текст – ул “төгәлләнгәнлеккә ия булган, язма документ буларак объективлашкан һәм шуңа хас рәвештә әдәби эшкәртелгән сөйләм процесссының нәтиҗәсе; исемнән һәм үзара төрле лексик, грамматик, логик, стилистик чаралар белән бәйләнгән үзенчәлекле берәмлекләр тезмәсеннән (синтаксик бөтеннәрдән)

---

[26] Теория текста: учеб. пособие / Ю.Н. Земская, И.Ю. Качесова, Л.М. Комиссарова, Н.В. Панченко, А.А Чувакин. – Москва: Флинта, Наука. – 2010. – С. 15.

[27] Белянин В.П. Введение в психолингвистику. – М.: Черо, 2004. – С. 109.

[28] Никитина Е.И. Русская речь: Учеб. Пособие по развитию связной речи для 5-7 кл. общеобразоват. учеб. заведений. – М.: Просвещение, 1993. – С. 16.

[29] Ильин И.П. Постструктурализм. Деконструктувизм. Постмодернизм. – М., 1996. – С. 224.

төзелгән әсәр, билгеле бер максатка хезмәт иткән һәм прагматик юнәлеше булган иң эре синтаксик берәмлек”[30].

А.А. Леонтьев текстны “сөйләмнең функциональ тәмамланган бердәмлеге” дип кыскача таныту белән чикләнә.[31]

В.В. Одинцовның тарафдары А.И. Горшков текстка түбәндәге билгеләмәне бирә: язмача яки телдән белдерелгән, тәртипкә китерелгән һәм тәмамланган, билгеле бер эчтәлеккә ия булып, берәр әдәби яки әдәби булмаган жанрга караган, башка берәмлекләрдән аерып куелган һәм кирәк чакта яңадан тудырыла алган сүзләр бердәмлеге (словесное целое)[32].

Коммуникатив стилистика тарафдарлары исә текстны аралашуның төп берәмлеге буларак өйрәнәләр. Мәсәлән, Н.С. Валгина күп аспектлылыгы белән аерылып торган текстны тел планы категорияләре ягыннан гына тикшерүне дөрес түгел дип саный. Галимә “җөмләләр тезмәсе”, “җөмләдән зуррак берәмлек” кебек төшенчәләрне текстка карата кулланып булмаганын раслый, чөнки алар, әлеге берәмлекнең төзелешен, материаль тышчасын гына чагылдырып, аңа хас булган экстралингвистик сыйфатларны һәм сөйләмдә катнашучыларны игътибарсыз калдыра[33]. Автор фикеренчә, тулы канлы әдәби әсәр кебек мәгънәви һәм структур яктан тәмамланганга күрә, текст иң югары дәрәҗәдәге коммуникатив берәмлек дип танылырга хаклы[34].

Н.С. Болотнова фикеренчә, текст – ул концептуаль нигезле (ягъни идеясе, концепты булган), билгеле бер аралашу даирәсендә коммуникатив юнәлешкә, информатив-мәгънәви һәм

---

[30] Гальперин И.Р. Грамматические категории текста (опыт обобщения) // Серия литературы и языка. – Том 36. – №6. – 1977. – С. 18.

[31] Леонтьев А.А. Высказывание как предмет лингвистики, психо лингвистики и теории коммуникации. // Синтаксис текста. – М.: Наука, 1979. – С. 28.

[32] Горшков А.И. Русская стилистика. Стилистика текста и функциональная стилистика: учеб. для вузов. – М.: АСТ: Астрель, 2006. – С. 65.

[33] Валгина Н.С. Теория текста: Учебное пособие. - М: Логос, 2004. – С. 6.

[34] Шунда ук. – Б. 9.

прагматик асылга ия булган сөйләм әсәре[35]. Авторның әлеге билгеләмәсендә игътибар үзәгенә текст эшчәнлегенең аралашудагы роле куела. Бу очракта бары тик тулаем текст күз алдында тотыла, чөнки автор интенциясе (идеясе), гомуми коммуникатив стратегия белән сөйләм тактикасы, текстның коммуникативлык үзлеге һәм барлык системалы сыйфатлары бу күләмдә генә тулысынча ачыла.

Шул ук вакытта, мәдәни тикшеренүләр нигезендә дискурс төшенчәсенә игътибар арту сәбәпле, текстны башка планга күчергән телчеләр дә бар. Мәсәлән, В.Е. Черняховская, текст төшенчәсен дискурсив анализ күзлегеннән тикшереп, аның хәзерге вакытта иң югары бәйсез коммуникатив берәмлек буларак карала алмавын, ә бәлки дискурс системасында, ягъни экстралингвистик фонда һәм аннан өстен торып яшәгәнен ассызыклый.[36] Үзенең хезмәтендә автор текстны ике гасыр чигендә туган тикшеренү парадигмасы кысаларында яңа лингвистик категория – дискурс белән бәйләнештә анализлый. Әлеге дискурс системасында текстның процессуальлек сыйфаты ачыклана, катнаш (креоль һәм күпкодлы) текст төрләренә хас үзенчәлекләр күрсәтелә, интертекстуальлек һәм интердискурсивлык төшенчәләре аңлатыла.

Моңа карамастан, без дискурс белән текст терминнарын аерып өйрәнү ягында торган Н.С. Валгина, А.А. Ворожбитова[37], Е.С. Кубрякова[38], М.К. Бисимилаева[39] кебек галимнәрнең фикере белән килешәбез. Хәзерге вакытта дискурс термины психологик, социокультур, прагматик һ.б. экстралингвистик факторлар

---

[35] Болотнова Н.С. Филологический анализ текста. – М.: Флинта: Наука, 2009. – С. 104.

[36] Чернявская В.Е. Лингвистика текста: поликодовость, интертекстуальность, интердискурсивность: учеб. пособие. – М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2009. – С. 12.

[37] Ворожбитова А.А. Теория текста: Антропоцентрическое направление: учеб. пособие. – М.: Высшая школа, 2005. – 367 с.

[38] Кубрякова Е.С., Александрова О.В. Виды пространств текста и дискурса // Категоризация мира: пространство и время. Материалы научной конференции. – М., 1997.

[39] Бисималиева М.К. О понятиях «текст» и «дискурс» // Филологические науки. – 1999. – №2.

җыелмасында каралган, ягъни “тормыш белән чолганган” текстны белдерә. Әлеге терминнарның икесе дә яшәргә хаклы һәм тел белемендә бер дәрәҗәдә яшәп киләләр дә, ләкин аларның кулланылу даирәсе төрле. Дискурс сөйләм тудыруның реаль процессы белән бәйле булса, текст әлеге гамәлнең нәтиҗәсе буларак карала. Шул ук вакытта әлеге ике төшенчә сөйләм формалары ягыннан да аерылып торалар: “дискурс” терминын телдән иҗат ителгән әсәрләргә карата ешрак кулланалар, ә “текст” термины күбрәк язма әсәрләрне аңлата.

## Әдәби текст һәм аңа хас сыйфатларны билгеләү үзенчәлеге

Югарыда күренгәнчә, текстка бирелгән билгеләмәләр тикшерү методына бәйле рәвештә үзгәреп торалар: текстның аралашудагы ролен өйрәнүче телчеләр аның кабул ителүенә һәм интерпретациясенә күбрәк игътибар итсәләр, текстның оешу закончалыкларын һәм структур принципларын тикшерүчеләр аның бәйләнгәнлек (связность) һәм бердәмлек (единство) сыйфатларына басым ясыйлар. Өстенлек бирелгән принципка карап, галимнәр текстны гади җөмләләр тезмәсеннән аерып торган төрле билгеләрне күрсәтәләр.

И.Р. Гальперин текстка хас булган категорияләрне, иерархиясен билгеләмичә, ике төркемгә бүлә: 1) *семантик* категорияләр: информативлык, тирәнлек, пресуппозиция, прагматиклык; 2) *структур* категорияләр: интеграция, тоташканлык, ретроспекция, проспекция, партитурлык, континуум.[40]

А.И. Горшков Ю.М. Лотман карашларын үстереп, текстның 7 аермалы билгесен күрсәтә: билгеләнгәнлек, чикләнгәнлек, структуралылык, информативлык, кабат тудырыла алу, билгеле бер жанрга карау, тәмамланганлык. Автор искәрткәнчә, кайбер текстларга әлеге билгеләрнең барысы да берьюлы хас булмаска мөмкин, ләкин мондый очраклар бу билгеләрне дә, текстның үзен дә юкка чыгармый. Мәсәлән, “Велосипед сатыла”, “Керү” кебек реклама яки элмә такталар да,

[40] Гальперин И.Р. Грамматические категории текста (опыт обобщения) // Серия литературы и языка. – Том 36. – №6. – 1977. – С. 523.

галим фикеренчә, текст буларак каралырга хаклы, чөнки аларда тулы күләмдә текстның дүрт төрле билгесе ачык чагыла: билгеләнгәнлек, чикләнгәнлек, информативлык һәм кабат тудырыла алу.[41]

Текст стилистикасын коммуникатив яктан өйрәнгән Н.С. Болотнова исә аның сыйфатларын һәм категорияләрен аерып карарга тәкъдим итә. Текстның *системалы сыйфатларына* галимә коммуникативлык белән билгеләнгән информативлык, структуралылык, регулятивлык (прагматиклык) һәм интегративлык төшенчәләрен кертә, ә *бердәмлек* белән *бәйләнгәнлек* сыйфатларын аерым тикшерә.[42]

Текст *категорияләренә* килгәндә, Н.С. Болотнова, фәлсәфәдәге гомуми төшенчәләргә таянып, вакыт, урын-вакыт (хронотопны), вакыйга һәм динамиклык категорияләрен билгели, соңгысы эчендә субъективлык, адресланганлык билгеләрен һәм автор белән адресат образларын аерып чыгара.[43]

Л.Г. Бабенко да текстның категорияләре белән сыйфатларын аерым тикшерү яклы, ләкин аның хезмәтләрендә гомумән башка төрле бүленеш күзәтелә. Аерым алганда, автор бердәмлек белән бәйләнгәнлекне һәр текстка хас булган универсаль категорияләргә кертеп карый.

*Бердәмлек* категориясе текстның эчтәлек ягын ачыклый һәм югары дәрәҗәдәге прагматиклыгы белән аерылып тора. Экспрессивлык, информативлык, интегративлык, тәмамланганлык, хронотоп, автор белән персонаж образлары, модальлек, эмотивлык кебек төшенчәләр исә текстның бердәмлеген тәэмин итә торган элемент буларак бу категория эчендә каралалар. *Бәйләнгәнлек* категориясе исә текстның белдерелү (форма) ягына карый һәм, лингвистик нигезле булганга, синтагматиклыгы белән аерылып тора. Ретроспекция

---

[41] Горшков А.И. Русская стилистика. Стилистика текста и функциональная стилистика: учеб. для вузов. – М.: АСТ: Астрель, 2006. – С. 59-62.

[42] Болотнова Н.С. Филологический анализ текста. – М.: Флинта: Наука, 2009. – С. 136.

[43] Шунда ук. – Б. 162.

белән проспекция, бүленүчәнлек төшенчәләре аның күрсәткечләре буларак тикшерелә.

Алда каралган категорияләрдән тыш, Л. Г. Бабенко, башка телчеләрнең фикерләрен дә исәпкә алып, әдәби әсәр текстына 9 төрле сыйфатның хас булганын күрсәтә: кешене үзәккә кую, социологиклык, диалогиклык, эчке һәм тышкы форманың бердәмлеге, җәелгәнлек һәм логиклык, статиклык һәм динамиклык; эстетика белән билгеләнгән прагматиклык, концептуальлек һәм образлылык; интерпретациягә бирелү.[44]

Нәтиҗә ясап әйткәндә, тел белемендә текстны гади җөмләләр тезмәсеннән аерып торган күптөрле сыйфатлар күрсәтелә. Галимнәр арасындагы фикер төрлелеге исә күп очракта әлеге гомуми төшенчәләрне классификацияләгәндә чагылыш таба.

## Әдәби текстның төп берәмлекләре

Лингвистик категорияләр системасында текст автор модальлеге белән беркетелгән, функциясе, эчтәлеге һәм структурасы ягыннан тәмамланган сөйләм берәмлеге буларак килеп баса. Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрнең стилистик билгеләре бары тик текст бердәмлегендә генә ачыла. Һәрбер текст – ул иң элек җөмләләр һәм хәбәрләмәләр җыелмасы. Соңгыларыннан мәгънәви һәм структур элемтәләр нигезендә фраза берләшмәләре оеша, ә алардан тулы канлы сөйләм әсәре барлыкка килә. Икенче төрле әйткәндә, текст төзү дәвамында телнең максималь берәмлекләре (җөмләләр) сөйләмнең минималь берәмлекләренә (хәбәрләмәләргә) әвереләләр, ә соңгылары, семантик-структур блокларга берләшеп, төрле сөйләм төзелмәләрен барлыкка китерәләр. Нигезендә хәбәрләмәләрнең күпсанлы вариантлары яткан әлеге тезелмәләр ярдәмендә төрле текст типлары оеша.

Текстка лингвистик анализ ясау һәм текст берәмлекләрен аеруда өч төрле юнәлешне күрсәтергә мөмкин:

1. **Функциональ-лингвистик** юнәлештә текст тел системасына таянып, ягъни тел структурасы ягыннан

[44] Бабенко Л.Г. Лингвистический анализ. – Екатеринбург: Изд-во Урал. ун-та, 2000. – С. 55-64.

анализлана. Текстны төзегән тел чаралары автор тарафыннан сайлап алына һәм аның дөнья турындагы күзаллауларын чагылдыра. Моннан чыгып, текст берәмлекләренә иерархик яктан оешкан һәм текстта төрләндереп кулланылган тел берәмлекләре (фонема, морфема, лексема, сүзтезмә һәм җөмләләр) кертелә, ләкин алар яңача – текстта башкарган вазыйфалары ягыннан тикшерелә.

2. **Текстуаль** (структур-семантик) юнәлештә текст үзенең аерым берәмлегенә – катлаулы синтаксик төзелмәгә ия булган һәм әйтерсең үз эченә ябылган уникаль структур берләшмә итеп кабул ителә. Әмма аның функциональлеге һәм авторга гына хас булган үзенчәлекләре игътибардан читтә кала һәм тикшерү барышында исәпкә алынмый.

3. **Функциональ-коммуникатив** (система-эшлекле) юнәлеш 2 тезиска таяна: 1) һәрбер текст артында аның авторы, кабатланмас тел иясе тора; 2) һәрбер текст җәмәгатьчелеккә җайланган, адресатка юнәлтелгән була. Бу яктан тикшергәндә, текст эчендә лингвистик һәм экстралингвистик сыйфатларга ия булган, функциональ һәм коммуникатив яктан аерылган динамик текст берәмлекләре аерып чыгарыла.[45]

Мәсәлән, текстны коммуникатив яктан тикшергән Н. С. Болотнова аның *информацион-мәгънәви* һәм *прагматик* дәрәҗәләрен аерып күрсәтә һәм һәрберсенә үзенчәлекле эчке катламнарга бүленгән текст берәмлекләре хас дип раслый.[46]

Н. С. Болотнова тәкъдим иткән модель эчендә һәр дәрәҗә берәмлекләре вертикаль буенча үзара ассоциатив, ә горизонталь буенча иерархик мөнәсәбәттә торалар. Гомумән алганда, бу берәмлекләр системасы катлаулы структурасы һәм коммуникатив эшчәнлеккә юнәлтелүе, текстның ике катлы табигатен чагылдыруы, лингвистик һәм экстралингвистик берәмлекләрнең аерып бирелүе белән үзенчәлекле. Шул ук вакытта, галимнәр әлеге бүленештә текст берәмлек-ләренең

---

[45] Художественный текст в современной лингвистической парадигме: учебно-методич. пособие для вузов. – Воронеж: Изд-во унив-та, 2007. – Б. 12-14.

[46] Болотнова Н.С. Филологический анализ текста. – М.: Флинта: Наука, 2009. – С. 259-265.

артык вакланганлыгын, конкрет текст структурасына беркетелмәгәнен һәм гамәли яктан куллану өчен уңайсыз булуын да искәртеп үтәләр.[47]

Югарыда билгеләнгән функциональ-лингвистик, текстуаль һәм функциональ-коммуникатив аспектларның алымнары әдәби әсәр анализлауның аерым этапларында, тикшерү максатына карап, төрлечә кулланылырга мөмкин.

Функциональ яктан тикшергәндә, сөйләмнең аерым сүз, хәтта җөмләләрдән түгел, ә бары тик тулаем текст эчендә генә вазыйфасын тулысынча үти ала торган хәбәрләмәләрдән (высказывание) оешканы күренә, чөнки бер үк җөмләне төрле контекст эчендә төрле интонация, ритм һәм логик басым ярдәмендә мәгънәне тулысынча үзгәртерлек итеп укып була.

**Хәбәрләмә** – ул реальләшкән җөмлә, лексик эчтәлеккә һәм билгеле бер максатка ия булган сөйләм берәмлеге. Һәр хәбәрләмә – ул җөмлә, ләкин һәрбер җөмлә хәбәрләмә булмаска мөмкин. Бер җөмлә эченә берничә хәбәрләмә-хәбәр сыя ала. Текст эчендә без тел катламына караган җөмләләр белән түгел, ә сөйләм берәмлеге – хәбәрләмә белән эш итәбез.

Коммуникатив сыйфатларына карап, хәбәрләмәләрне шартлы рәвештә икегә бүлеп тикшерәләр[48]:

1) Мәгълүмати (информацион) хәбәрләмәләрдә эчтәлек ягына караган тасвирламалы, хикәяләү, анализлау һ. б. төр фактологик һәм концептуаль мәгълүмат чагыла. Аларның функциясе – хәбәр итү, билгеле бер мәгълүмат ташу.

2) Верификатив хәбәрләмәләр исә раслау, кире кагу, контраргументлар белдерү һәм адресатка тәэсир итү өчен кулланылалар. Шуңа күрә аларның функциясе реаль яки күз алдында тотылган әңгәмәдәшнең фикеренә реакция формалаштыруга кайтып кала, ягъни эмоциональ тәэсиргә корыла. Бу төр хәбәрләмәләр, эмоциональ нигезгә һәм бәяләүгә корылып, еш кына текст артындагы мәгълүматны тапшыралар.

---

[47] Бабенко Л.Г. Лингвистический анализ текста. – Екатеринбург: Изд-во Урал. ун-та, 2000. – С. 50.

[48] Валгина Н.С. Теория текста: Учебное пособие. – М.: Логос, 2004. – С. 28.

Мәгълүмати хәбәрләмәләр хикәяләү, тасвирлама һәм хөкем йөртүгә корылган текстларның нигезендә яталар, ә верификатив хәбәрләмәләр, шушы ук төр текстларның эченә кереп, аларны диалоглаштыралар, ягъни билгеле бер мөнәсәбәт һәм хис-кичереш өстиләр. Төрле типтагы текстларда, авторның максатына, сурәтләү предметына һ. б. сәбәпләргә бәйле рәвештә, ике төр хәбәрләмәнең берсе өстенлек ала һәм төрле чаралар ярдәмендә белдерелә.

Текстның оешуы өчен хәбәрләмәләрнең алышынып үсә баруы кирәк. Коммуникатив планда һәрбер хәбәрләмә икенчесенә бәйләнә һәм мәгълүматны тулырак ачуга юнәлтелә. Автор әйтергә теләгән фикер адымлап, иске мәгълүматтан яңасына, билгеледән билгесезгә таба аңлатыла бара. Моның нәтиҗәсендә тема белән реманың чиратлашуы, тезмәсе яки чылбыры барлыкка килә. Хәбәрләмәләрнең рема төзелмәләре адресатка яңа мәгълүмат бирә һәм аны алга этәрә, тема төзелмәләре исә аңа таяныч нокталары булып тора һәм, аерым хәбәрләмәләрне бер-берсенә беркетеп, информатив, коммуникатив һәм структур дәвамчанлыкны тәэмин итә.[49]

Текстның икенче семантик-синтаксик берәмлеге – фраза берләшмәләре яки **катлаулы синтаксик бөтеннәр** (ССЦ) – ике яки күбрәк хәбәрләмәнең тематик һәм структур яктан берләшүе һәм тема-рема алышынуы ярдәмендә барлыкка килә. Фраза берләшмәләре үз чиратында, контактлы һәм дистактлы тәэсир иткән мәгънәви һәм грамматик элемтәләр ярдәмендә, текстка тулылык бирә торган тагын да эрерәк **фрагмент-блокларга** берләшәләр.

Хәбәрләмәләрнең тагы да эрерәк берәмлек оештыру процессын күптөрле тема-рема чиратлашу модельләренә таянып тәфсилләбрәк тә аңлатырга мөмкин. Мәсәлән, Г. Я. Солганик прозаик строфаларның логик элемтә ысуллары буенча чылбырлы, параллель һәм катнаш төрләрен аерып чыгара, алар эчендә тагын 20дән артык төрне билгеләп, һәрберсен аерым алып анализлый[50].

---

[49] Теория текста: Учебное пособие. – М.: Логос, 2004. – – С. 42.

[50] Солганик Г.Я. Синтаксическая стилистика. — М.: Высшая школа, 1991. – 182 с.

Шул ук вакытта кайбер галимнәр әлеге бүленешне артык схематик һәм катгый булу аркасында кабул итмиләр. Аерым алганда, В.В. Одинцов үзенең китабында Г. Я. Солганик системасын семантик аспекттан читкә киткәнгә, строфаның композициясен аның башламнарына һәм синтаксик структурага таянып кына тасвирлаганга, текст берәмлекләрен берничә композицион планда тикшергәнгә күрә тәнкыйтьләп чыга[51]. Үз чиратында В.В. Одинцов, график, синтаксик һәм мәгънәви принципларга таянып, текстны төзи торган 4 төрле логик бердәмлекне аерырга тәкъдим итә: характеристика һәм тасвирлама (статик); хәбәр һәм хикәяләү (динамик бердәмлекләр).[52]

Шулай итеп, хәзерге тел белемендә текст берәмлекләрен билгеләүдә төрле карашлар булуы ачык. Аларның кайберләре бер-берсенә каршы торалар, ә кайберләре бер-берсен тулыландырып киләләр. Моңа карамастан, һәрбер бүленешнең уңай һәм тискәре якларын күрсәтергә мөмкин, шуңа күрә тикшеренүчеләр аларны үз максатларына туры китереп, камилләштереп кулланалар. Безнең хезмәттә исә текстның тышкы структурасында иң әһәмиятле урында торган берәмлекләр – синтаксик бөтен һәм абзацларның кулланылышы тикшереләчәк.

Гомумиләштереп алганда, хәзерге тел белемендә текст теориясенең актуаль мәсьәләләре арасыннан текстка төшенчә бирү, аның сыйфатларын һәм берәмлекләрен билгеләү аерым игътибарга лаек. Алар барысы да текстның структурасын, ягъни ни рәвешле төзелгәнен һәм кайсы элементлардан торганын ачыклауда әһәмиятле роль башкаралар.

## Әдәби текстның төзелеше

**Текст төзелеше** – ул әсәрнең эчке һәм тышкы яктан оешуы, элементларының үзара бәйләнеш ысуллары. Билгеле бер структурага ия булу әсәрнең бердәмлеген, эчтәлекне белдерә алуын тәэмин итә.

---

[51] Одинцов В.В. Стилистика текста. – М.: Наука. – 1980. – С. 97-102.
[52] Шунда ук. – Б. 85-90.

Синтаксисның иң эре берәмлеге дип саналган текст күпьяклы структура тәшкил итә, аны өйрәнгән юнәлешләр исә нигезгә салынган төп тикшеренү принцибы белән аерылып торалар. Әлеге төрлелек текстны структур-мәгънәви берәмлекләргә таркатуда да ачык чагыла.

И.Р. Гальперин текстның ике төрле бүленешен билгели: күләм-прагматик һәм контекст-вариатив. Беренче принцип буенча текст эчендә китап, том, бүлек, бүлекчә, абзац һәм синтаксик бөтен кебек берәмлекләр аерып чыгарыла. Шулай ук текстта сөйләмнең 3 төрле актын билгели: автор сөйләме (хикәяләү, тасвирлау һәм хөкем йөртү), чит сөйләм (диалог, цитация) һәм уртак сөйләм[53].

А.И. Горшков текстның эчтәлек (содержание) һәм белдерелү (форма) планнары арасында бүленгән тема, идея, композиция, әсәр сюжеты һ. б. категорияләрне автор образы берләштерә һәм билгели дип раслый[54].

Структур элементларның элемтәгә керү кысаларына карап, текстның эчке һәм тышкы структуралары аерып чыгарыла. Ләкин әлеге ике төшенчә галимнәр тарафыннан төрлечә аңлатыла. Д.В. Салмина һәм Н.Н. Шубина фикеренчә, эчке структура – функцияләрен бирелгән текст кысаларында үтәгән һәм аның бердәмлеген оештырган элементлар җыелмасы, ә тышкы структура – уйланылган эчтәлекне экспликацияләүгә һәм “әдәби сүзле макрообраз”ны тудыруга хезмәт иткән чаралар берләшмәсе.[55]

Н.А. Николина әдәби текстны шулай ук ике катламга – эчке һәм тышкы композициягә аерып тикшерә. Башкалардан аермалы буларак, галимә тышкы композицияне архитектоника белән тәңгәлләштерә, ә эчке композицияне әсәрнең эчтәлеге,

---

[53] Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования.– М.: Комкнига, 2007.–С.25.

[54] Горшков А. И. Русская стилистика. Стилистика текста и функциональная стилистика: учеб. для вузов. – М.: АСТ: Астрель, 2006. – С. 244-248.

[55] Салмина Д.В., Шубина Н.Н. Лексико-синтаксическая основа коммуникативно-смыслового членения текста // Текстовые реализации и текстообразующие функции синтаксических единиц: Межвузовский сборник научных трудов. – Л.: ЛГПИ, 1988. – С. 26.

образ һәм характерлар системасы, конфликт үзенчәлекләре һ. б. белән бәйли.[56]

Татар хикәяләренең текст структурасын ике якка – эчке һәм тышкы структурага аерып тикшерергә мөмкин. Әдәби әсәр текстының тышкы структурасын синтаксик бөтен, абзац кебек берәмлекләр һәм әсәрнең көчле позицияләре оештыра. Әмма эчтәлеккә бәйле булган тема-идея, образлар системасы һәм конфликт мәсьәләләре әдәбият белемендә каралырга тиеш, ә әсәрнең тел төзелешен һәм язучының стиль үзенчәлекләрен ачыклау өчен монологик текстларның хикәяләү, тасвирлау, хөкем йөртү өлешләрен һәм диалогик текстларны анализлау таләп ителә.

## Әдәби текстның тышкы структур үзенчәлеге

Әсәрнең **тышкы структурасы** аның архитектоникасы яки тышкы композициясе белән аваздаш була. Текстның тышкы структурасы яки архитектоникасы әсәрнең мәгънәсен өлешләргә бүлеп бирү алымы булып тора, авторга укучы игътибары белән идарә итү мөмкинлеге бирә.

Хәзерге татар хикәяләренең структур төзелешен һәм прагматик үзенчәлекләрен ачыклау өчен текст берәмлекләреннән без абзац белән синтаксик бөтенгә анализ ясауны максат итеп куйдык, чөнки бу берәмлекләрнең беренчесендә текстны төзегән авторга, ә икенчесендә текстка хас прагматик куелыш ачык чагыла.

*Синтаксик бөтен.* Бердәм организм буларак оешкан текст эчендә дә тотрыклы берәмлекләр билгеләргә мөмкин. Шуларның иң кечкенәсе дип күпчелек галимнәр прозаик сөйләмдәге мөстәкыйль җөмләләрнең мәгънәви һәм синтаксик бердәмлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән прозаик строфаны күрсәтәләр. Бу термин татар тел белемендә **синтаксик бөтен** төшенчәсе белән билгеләнә.

Синтаксик бөтен интонацион яктан бер бөтен тәшкил итә, мәгънәви яктан фикер, хәбәр итү, тема бердәмлегенә ия була.

[56] Николина Н.А. Филологический анализ текста: Учебное пособие для студентов высших учебных заведений. – М.: Издательский центр «Академия», 2003. – С. 46.

Тулаем әсәрнең мәгънәви бөтенлеге, кисәкләренең бердәмлеге бигрәк тә матур әдәбият әсәрләре өчен хас. Синтаксик бөтен фикернең бердәмлеге белән генә түгел, аның төгәлләнгән булуы белән дә аерылып тора. Аерым җөмлә бик сирәк мөстәкыйль була, ул бары тик синтаксик бөтен эчендә генә тулы канлы тормыш белән яши башлый, шуңа күрә синтаксик бөтен фикернең тагын да тулырак үстерелеше белән характерлана.

Сөйләм процессындагы хөкемнәр кебек, текст эчендәге җөмлә һәм хәбәрләмәләр үзара ике төрле бәйләнергә мөмкин[57]:

1) *Чылбырлы* бәйләнештә алдагы хөкемнең предикаты яки субъекты кабатлана яисә ачыклана; алдагы җөмләдәге предикат яңа җөмләдә субъект, ә субъект предикат булып килә.

2) *Параллель* бәйләнештә хөкемнәрнең кабатланып килгән кисәге бер үк функцияне үти: һәрбер хөкемдә я субъект, я предикат булып килә. Яңа хөкемдә субъект һәм предикат өлешчә генә дә кабатланырга мөмкин.

Моннан чыгып, тел белемендә текстта кулланылган синтаксик бөтеннәрне ике төркемгә аерып өйрәнү кабул ителгән: чылбырлы һәм параллель бәйләнештә торган синтаксик бөтеннәр. Алар бер-берсеннән мәгънәви үзенчәлекләре һәм тел чаралары белән аерылып торалар.

**Чылбырлы бәйләнеш** сөйләмдә фикернең эзлекле хәрәкәтен, үсешен чагылдыра. Җөмләдәге сүзләр төрле мәгънәви йөккә ия булалар, ә логик басым төшкән, төп мәгънәне белдергән сүз гадәттә яңа җөмләдә кабатлана һәм үстерелә. Фикерне үстергән хөкемнең предикаты предмет турында яңа мәгълүмат җиткерә. Җөмләдә аерылып торган, акцентланган сүз хөкемнең предикаты була һәм үз чиратында яңа предикат белән ачыклана. Бәйләнешле сөйләмдә шуның нигезендә өзлексез хәрәкәт, фикер чылбыры барлыкка килә.[58]

---

[57] Солганик Г.Я. Стилистика текста. — М.: Флинта, Наука, 1997. – С. 24-30.

[58] Солганик Г.Я. Синтаксическая стилистика. — М.: Высшая школа, 1991. – Б. 42-43.

Әлеге бәйләнештә җөмләнең актуаль кисәкләренә бүленеш тә әһәмиятле роль башкара[59]. Сөйләм предметы фикер хәрәкәтенең башлануын, ә сөйләм яңалыгы аның нигезен, үсешен белдерә. Ләкин фикер үсеше бер җөмлә белән генә тәмамланмый, сөйләм яңалыгы киләсе җөмләдә сөйләм предметына әверелә һәм анда башка яңалык таләп итеlә башлый.

Формаль-мәгънәви төзелеш ягыннан тикшергәндә, җөмләләрнең күпчелегендә өч кисәк күзәтелә: субъект (ия), предикат (хәбәр) һәм объект (тәмамлык). Алар җөмләне структур яктан оештырып торалар, аны башка җөмләләр белән бәйләүдә дә гаять зур роль уйныйлар. Субъект – объект мөнәсәбәтләре телдә иң универсаль категорияләр дип саналганга[60], телдә ия – тәмамлык, тәмамлык – ия, тәмамлык – тәмамлык кебек чылбырлы бәйләнешләрнең киң кулланылганы табигый.

Шулай итеп, чылбырлы бәйләнештәге җөмләләр эчке (логик элемтәләр нигезендә) һәм тышкы яктан (тел чаралары ярдәмендә) бер-берсенә тыгыз бәйләнгәннәр.

**Параллель бәйләнештәге** синтаксик бөтеннәр уртак темага караган җөмләләр нигезендә барлыкка киләләр. Алар күбесенчә табигать күренешләрен һәм портретларны бирү өчен кулланылалар.

Һәрбер җөмләне җөмлә итүче шарт – аның предикатив үзәге. Шуңа күрә һәрбер параллель килгән җөмләдә предикатив үзәк хәлиткеч рольне үти. Гадәттә әлеге үзәкләрнең параллелизмы структур һәм мәгънәви бердәмлек барлыкка китерә дә инде. Мондый бәйләнеш шигырьләрдә, публицистик стильдә аеруча киң кулланыла, ләкин проза әсәрләре өчен дә ул ят түгел.

---

[59] Сафиуллина Ф.С. Порядок слов в современном татарском литературном языке. Автореферат дисс. ... канд. филол. наук. – Казань, 1965. – 21 с.

[60] Жирмунский В.М. О целесообразности применения в языкознании математических методов // Лингвистическая типология и восточные языки. – М.: Наука, 1965. – С. 109.

*Абзац.* Текстны хәбәрләмә белән синтаксик бөтеннәргә бүлеп карау аның структурасын семантик-синтаксик берәмлекләргә аеруны күрсәтә. Ләкин тел белемендә текстларны тагын бер төрле – композицион-стилистик яктан бүлү дә киң таралган. Беренче бүленеш текстның күбрәк прагматик куелышына бәйле булса, икенчесе тулысынча авторның прагматик максатлырыннан тора. Текст никадәр стандарт һәм калыплы булса, әлеге ике төрле бүленеш шулкадәр бер-берсенә якыная һәм тәңгәлләшә.[61]

Текстның композицион-стилистик берәмлеге дип **абзац** санала. Ләкин аның барлык эчке үзенчәлекләре синтаксик бөтен белән чагыштырганда гына ачыла. Тышкы яктан бер дәрәҗәдә охшаш булсалар да, әлеге ике берәмлекнең эчке табигате күп яктан аерыла.

Аерым алганда, синтаксик бөтен башлам җөмлә белән ачыла торган тема-рема чиратлашуыннан оеша, ә абзацта әлеге төп фраза төрле урында торырга, сан буенча да бердән күбрәк булырга мөмкин. Абзацның күләмен һәм формасын билгеләү дә тулысынча автор ихтыярында.

Моннан тыш, синтаксик бөтен эчендәге җөмләләрне, тыныш билгеләрен үзгәртеп, бер зур катлаулы җөмләгә берләштереп була, ә абзац, синтаксик табигатькә ия булмаганга, мондый үзгәрешләргә бирешми.

Синтаксик бөтеннең чикләре дә абзацка күп очракта туры килми. Бер абзац эчендә микротемалары белән берләшкән берничә синтаксик бөтен булган кебек, бер синтаксик бөтен берничә абзацка таркатылырга да мөмкин. Әлеге бүленеш текстның кайсы стильгә караганына, аеруча авторның әсәрне язганда куйган максатларына һәм шәхси стиль үзенчәлекләренә бәйле була. Мәсәлән, Г. Ибраһимов һәм К. Нәҗми абзацлары күләмле булуы белән аерылып торган, Ә. Еники исә кыскалыкка омтылган; Л. Н. Толстой үзенең әсәрләрен озын абзацлар белән язган, ә А. Чехов белән К. Паустовский текстны кечкенә композицион өзекләргә бүлергә яратканнар.

[61] Валгина Н.С. Теория текста: Учебное пособие. - М: Логос, 2004. – С. 60.

Шулай итеп, текстның синтаксик бөтен белән абзацка бүленешендә төрле аермалар күзәтелә. Аларның төп сәбәбе текстны бүлүдәге субъектив яки объектив якның өстенлегенә кайтып кала: абзацларга бүленеш, автор теләгенә бәйле булганга, төрлечә үзгәрергә мөмкин булса, синтаксик бөтеннәргә бүленеш, текст үзенчәлекләренә бәйле булганга, һәрвакыт үзгәрешсез кала.[62]

Моңа карамастан, синтаксик бөтен белән абзац еш кына бер-берсенә тәңгәл килергә дә мөмкин. Материалны тапшыру логик-мәгънәви юл белән барганда һәм абзац белән синтаксик бөтеннең чикләре микротемалар арасындагы күчешне билгеләгән очракта аларның күләме бер-берсенә гадәттә туры килә. Мондый очракларны тел белемендә *тематик* яки *классик* абзац дип атау кабул ителгән.

Тематик абзацларның төзелешендә типик очракларны билгеләргә мөмкин. Шуларга таянып, Н.С. Валгина аларның аналитик-синтетик, синтетик-аналитик һәм кысалы (рамкалы) төрләрен аерып күрсәтә.[63]

Абзацларны бүлүгә китергән төп сәбәпләр арасыннан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

– бер микротема икенчесе белән алышына яки яңа тема башлана;
– мәгълүмат бу текст кысаларында әһәмиятле була;
– деталь эмоциональ аерып куела, ассызыклана;
– фразаларны бергә куллану логик эзлексезлек тудыра, мәгънәгә зарар китерә.

Шулай итеп, әсәр текстында урын алган абзац композицион-стилистик үзенчәлекләрне һәм авторның прагматик максатларын чагылдыра. Тематик абзацлар исә синтаксик бөтен белән тәңгәл килгән өлешләрне үз эченә ала.

*Әсәр исемнәре.* Әсәрнең иң көчле позициясендә торган элементы – аның автор тарафыннан бирелгән атамасы.

---

[62] Валгина Н.С. Теория текста: Учебное пособие. - М: Логос, 2004. – Б. 62.

[63] Шунда ук. – Б. 63.

Әсәр исеме, примитив дәрәҗәдә булса да, үзенә күрә бер текст яки субтекст[64], хикәяләүгә кертеп җибәрә һәм идеягә ишарә итә торган үзәк, текст мәгълүматын җыеп биргән, текст структурасының мәгънәви детерминантасын һәм әсәрнең эмоциональ тоны чагылган көчле позиция булып исәпләнә[65].

Әсәрнең исеме белән текст үзара тыгыз мөнәсәбәттә тора. Исемгә чыгарылган сүз текстта гомумән урын алмаска да мөмкин, ләкин күпчелек очракта ул әсәр эчендә берничә тапкыр кабатлана һәм идеяне аңлауга ачкыч ролен үти ала.

Әсәр исемнәрен прагматик яктан тикшергәндә, сөйләм актлары теориясенең казанышларын куллану да уңышка ия. Әлеге теория буенча әсәр атамалары, сөйләм актының бер өзеге буларак, ике төрле функция үти: информатив (интеллектуаль мәгълүмат тапшыруга хезмәт итә) һәм прагматик (мәгълүматның адресаты, кабул итүчесе булып торган укучының үз-үзен тотышына һәм психикасының эмоцияләр өлкәсенә тәэсир итә). Прагматик функция эченә шулай ук рекламалау һәм эмоцияләр белдерү вазыйфалары да керә. Еш кына информатив һәм прагматик функцияләр тыгыз бәйләнештә торалар, ләкин берсе гадәттә алгы планга чыга. Газета мәкаләләрендә, мәгълүмат тапшыру төп роль уйнаганга, информатив функция беренче урында торса, әдәби әсәр исемнәре һәрвакыт диярлек прагматик функциягә таянып сайлана.

Әдәбият белемендә һәм текст теориясендә әсәр исемнәре тирәнтен өйрәнелгән, шуңа күрә күп галимнәр аларны төрлечә төркемләргә тәкъдим итәләр.

Мәсәлән, Н.А. Николина әсәр атамаларының мәгънәви аермаларына җентекләп туктала һәм аларның текст эчендә төрле функцияләр үти алганын ачыклый. Аның фикеренчә, әсәрнең исемнәре:

---

[64] Данилова Ю.Ю. Заглавия как «тексты-примитивы» (на материале поэтических текстов З.Н.Гиппиус) // III Международные Бодуэновские чтения (Казань, 23-25 мая 2006 г.): труды и материалы: в 2 т. – К.: Изд-во Казан. ун-та, 2006.– Т.1. – С.69-72.

[65] Бабенко Л.Г. Лингвистический анализ текста. – Екатеринбург: Изд-во Урал. ун-та, 2000. – С. 204.

- төп теманы чагылдыра, сюжет линиясен билгели яки хәлиткеч конфликтка күрсәтә;

- баш геройның исемен атый яки төп образны аерып куя;

- вакыйганың вакытын яки урынын күрсәтә;

- әсәрнең жанрына ишарә итә;

- персонажларның сөйләменнән өзекләрне чагылдыра;

- сорау яки боерык җөмләләр ярдәмендә адресатка мөрәҗәгать итә.[66]

Шулай ук галимә рус әдәбиятында исемнәр куюдагы тарихи үзгәрешләргә дә туктала. XIX-XX гасырларда иҗат ителгән әсәрләргә күзәтү ясап, автор аларның исемнәрен структур яктан 4 төргә аера: бер сүздән (күбесенчә исем сүз төркеменә караган), тезүле яки ияртүле бәйләнештәге ике сүздән һәм җөмләдән оешкан атамалар.[67]

Ф.С. Сафиуллина исә татар әдәбиятындагы әсәр атамаларын текст интеграциясе ягыннан тикшерә, аларның нинди формаль тел чаралары белән белдерелүенә һәм әсәр идеясен ачуда уйнаган роленә туктала. Автор фикеренчә, татар әдәбиятында XX гасыр башына кадәр куелып килгән кеше исемнәрен һәм күмәклек исемнәрне эченә алган атамалар хәзерге вакытта да кулланыла. Шул ук вакытта галимә соңгы елларда изафә бәйләнешле сүзтезмә яки җөмләнең бер өлеше белән аталган әсәр исемнәренең активлашканын билгеләп үтә. Язучылар әйткән фикерләр исә аларның әсәр исеменә булган мөнәсәбәтләрен һәм әсәргә туры килердәй исем табуның никадәр катлаулы икәнен ачык күрсәтүе белән игътибарга лаек.[68]

Тел белемендә әсәр атамаларын төркемләүдә башка карашлар да бар. Аерым алганда, Ф. Зөлкарнәев, татар телендә язылган шигырь һәм поэмаларга нигезләнеп, әсәр атамаларын

---

[66] Николина Н.А. Филологический анализ текста: Учебное пособие для студентов высших учебных заведений. – М.: Издательский центр «Академия», 2003. – С. 168-169.

[67] Николина Н.А. Күрс. хезм. – Б. 173.

[68] Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. – Б. 100-104.

исем – символ, исем – тезис, исем – цитата, исем – хәбәр, исем – киная, исем – хикәяләү дип 6 төркемгә бүлеп бирә[69].

Г.М. Нәбиуллина исә 70-90 нчы елларда иҗат ителгән башкорт прозасының структур үзенчәлекләрен анализлап, шул чор әдәби әсәр исемнәрен, эчтәлекне бирүгә бәйле рәвештә, 4 төргә аерып тикшерә:

1) герой исеме белән аталган исемнәр (“Абдрахим”, “Звездочка”);

2) геройның тормыш ситуациясен чагылдырган исемнәр (“Битва”, “Измена молодости”);

3) геройларның тормыш хәленә образлы бәя бирә торган исемнәр (“Скрытый клад”, “Осенняя мелодия”);

4) әсәрдә поэтик деталь вазыйфасын үтәгән предмет белән аталган исемнәр (“Гора”, “Пустая могила” һ. б.)[70].

Шулай итеп, әсәр исемнәре текст структурасында әһәмиятле роль уйный, шуңа күрә аның көчле позициясен тәшкил итә. Бу сәбәпле алар әдәбият теориясендә шактый өйрәнелгәннәр һәм төрле принципларга карап төркемләнгәннәр.

*Башлам һәм бетемнәр.* Әдәби әсәр структурасында төп роль уйнаган тагын ике элемент – башлам һәм бетем өлешләре. Укучы әсәр башламы белән текст эчтәлегенә кереп китә, ә бетем аның ноктасы булып яңгырый. Шуңа күрә әлеге структур элементлар никадәр уйланып төзелсә, текстның укучыга тәэсире шулкадәр зуррак, ә гомуми төзелеше шулкадәр камилрәк була.

**Башлам** хаклы рәвештә һәр әдәби әсәрнең укучыга исемнән соң турыдан-туры тәэсир итә торган мөһим элементы дип санала. Әсәр исемендә күрсәтелгән серле йомгак башламда сүтелә башлый һәм укучыны вакыйгалар әйләнмәсенә бөтереп алып китә. Чынлап та, әсәрнең ни рәвешле башлануы – аның гомуми эчтәлегенә, идея-проблеманың куелышына, сөйләм темпы һәм тонына юнәлеш биргән тәүге адым, “әсәрнең билгеле

---

[69] Зөлкарнәев Ф. Әверелеш. Шигырь парадокслары. – К.: Татар кит. нәшр., 1988. – Б.134.

[70] Набиуллина Г.М. Особенности структурной поэтики башкирской прозы 70-90-х годов: автореферат дис. ... канд. филол. наук. – Уфа, 2001. – С. 16.

бер мәгънәви, интонацион ачкычы, тиешле мәгънә һәм форма берлеге булганда – музыкаль әсәрдәге беренче аккорд”[71].

Милли әдәбиятыбыз оригиналь һәм традицион башламнарга бик бай, ләкин әлеге байлык бөтенләй өйрәнелмәгән диярлек. Чынлыкта исә башламнарның хәзерге татар әдәбиятта ничек кулланылганын, классик әсәрләрдәге уңышлы традицияләрнең сакланып-сакланмавын күзәтү бик актуаль мәсьәлә.

Татар прозасындагы башламнарны җентекләп өйрәнгән сирәк телчеләрдән берсе – Ф.С. Сафиуллина. Аның хезмәтләрендә күпсанлы мисаллар һәм төрле әдипләр белән әңгәмәләр нигезендә татар прозасында башламнарның функциясе, төрләре, язучыларның индивидуаль стиле белән бәйләнеше, әсәр башламының кайчан һәм ничек табылуы турында бай мәгълүмат тупланган.

Аерым алганда, галимә башлам җөмләне хикәяләүдәге иң мөстәкыйль җөмлә дип билгели, шуңа күрә еш кына аерым абзац булып формалашканын искәртә. Алга таба автор башламнарның әсәр бөтенлегендә уйнаган ролен анализлый, классик татар язучыларының башлам төзүдәге индивидуаль үзенчәлекләрен күрсәтә, татар прозасындагы башламнарның үсеш-үзгәреш тенденциясен билгеләргә омтыла. Хезмәттә шул чорда яшәгән татар язучыларының әсәр башламнарына мөнәсәбәте, аларның иҗат лабораториясе турындагы кызыклы мәгълүмат исә аерым игътибарга лаек.[72]

Ф.С. Сафиуллина әдәби әсәр башламнарының 4 төрен аерып күрсәтә, аларга түбәндәге күрсәткечләр хас булганын билгели:

1) Композицион башламнар вакыйгаларның иң югары ноктасын – кульминацион моментын чагылдыра. Бу төр башламнар әсәр композициясе белән тыгыз бәйләнештә тора һәм аны берникадәр үзенә буйсындыра. Бу төргә мисал буларак Г. Ибраһимовның “Тирән тамырлар”, “Кызыл чәчәкләр”, Ә. Ени-

---

[71] Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. – Б. 105.
[72] Шунда ук. – Б. 105.

кинең “Саз чәчәге” кебек классик әсәрләрнең башламнары китерелә.

2) Динамик башламнар хикәяләүнең киеренкелеген күзалларга мөмкинлек бирәләр, чынбарлыкта булган вакыйгаларның бер мизгелгә өзеп торып, язучының әсәренә күчеп утырган кебек тәэсир калдыралар (Г.Әпсәләмов “Сүнмәс утлар”, Ш.Камал “Буранда”).

3) Тасвирлама башламнарга интонацион яктан салмаклык, эпиклык, хикәяләү көе хас. Аларда күбесенчә табигать күренешләре сурәтләнә, алар урын һәм вакыт ягыннан хикәяләүгә фон булып торалар (Г.Ибраһимов “Безнең көннәр”, Ә.Еники “Әйтелмәгән васыять”).

4) Тематик башламнардагы берәр сүз әсәрнең буеннан-буена сөйләнәчәк вакыйганың үзәгендә тора, шуның аркылы еш кына исемгә чыгарылган төшенчә үстерелә, әсәрнең камил бердәмлеге хасил була (Ш.Камал “Уяну”, Ә.Еники “Җиз кыңгырау”).[73]

Безнеңчә, әлеге бүленештәге башлам төрләренең санын икегә калдыру уңышлырак, чөнки үзләренең тел күрсәткечләре, лингвистик үзенчәлекләре белән композицион башлам динамик төргә, ә тематик башлам тасвирлама төргә якын тора.

Шулай итеп, сөйләм темпына, әсәр тукымасына ничек кертеп җибәрүенә, мавыктыргыч яки салмак булуына, сурәтләү объектына һәм тел чаралары ярдәмендә ни рәвешле бирелүенә карап, әсәр башламнарын без ике төргә бүлеп карарга тәкъдим итәбез: динамик һәм тасвирлама.

**Динамик башламнар** әсәрнең тукымасына бәреп керәләр, укучыны геройлар һәм вакыйгалар белән бер мизгелдә уратып алалар. Монда персонажларның иң күпереп торган якларына гына игътибар бирелә, сюжет белән хәрәкәт алгы планга чыга, ә пейзаж яки портрет кебек тасвирлау фрагментлары арткы планга күчерелә.

**Тасвирлама башламнар,** динамик башламнардан аермалы буларак, табигать күренешләрен сурәтләүгә һәм персонажларга характеристика бирүгә багышлана, шуңа күрә

[73] Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. – Б. 105.

алар салмак интонация һәм эпиклык белән аерылып торалар. Әлбәттә, хикәя жанры таләпләре аркасында әлеге эпиклыкның күләме кими төшә, ләкин гомумән алганда интонация үзенчәлекләре саклана.

Динамик һәм тасвирлама башламнарның берсен сайлау тулысынча әдипнең иҗади максатларына бәйле була, чөнки бу өлешләрдә укучы билгеле бер мәгълүматны кабул итергә әзерләнә, ә автор күз алдында торткан тема-идеянең җеп очларын бирергә омтыла.

Яхшы гына башланган әсәрне тәмамлау күпкә җиңел кебек тоелса да, бу дөреслеккә бик туры килми, чөнки әсәрнең **бетеме** – авторның еш кына үз мөнәсәбәтен әйтеп яки сиздереп куйган урын, катлаулы сюжетның чишелеше яки тәмамланмаган хикәяләүнең дәвамына ишарә булып тора. Моннан ары, башлам белән бетемнең үзара мөнәсәбәтен искә алсак, әсәрнең башы һәм азагы никадәр әһәмиятле икәнен аңларбыз.

Кызганычка каршы, әдәбият белемендә һәм текст теориясендә әсәр бетемнәре башламнарга караганда да кимрәк дәрәҗәдә өйрәнелгән. Әсәр бетемнәрен төгәл һәм системалы рәвештә бүлү катлаулы, чөнки аларның һәрберсе уникаль, бу әсәр өчен генә хас. Моннан тыш, иҗади процессны кискен кысаларга кертү дә берьяклылыкка, шаблонлыкка китерергә мөмкин.

Моңа карамастан, төркемләү омтылышы өйрәнүне җиңеләйтә һәм язучыларның шәхси үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә, шуңа күрә без, тикшерелгән материалга нигезләнеп, хәзерге татар хикәяләрендәге бетемнәрне ике төрле принцип нигезендә төркемләргә тәкъдим итәбез.

1) Җөмләләрнең төзелешенә һәм кулланылган тел чараларына карап, хикәяләүле, риторик, туры сөйләмле һәм тезмә юллы бетемнәр бүлеп чыгарыла.

2) Мәгънәви үзенчәлекләргә һәм тәмамланганлык төсмеренә карап, нәтиҗәле, тәмамланмаган һәм серле (мифологик) бетемнәр билгеләнә.

Бетемнәрнең әлеге төрләре, әсәр башламнары кебек, көчле позициядә тора, шул сәбәпле зур мәгънәгә ия була һәм авторлар тарафыннан җентекләп эшкәртелә.

Гомумән, башлам белән бетемнәр әсәрнең тышкы структурасын төзүдә һәм адресатка прагматик тәэсир ясауда әһәмиятле роль уйныйлар. Бу үзенчәлек башлам белән бетемнәрнең күптөрле формаларында һәм төркемләү өчен катлаулы булган тел чаралары системасында да ачык күренә.

Шулай итеп, әсәр текстының тышкы структурасы аның архитектоникасы белән тыгыз мөнәсәбәттә тора. Синтаксик бөтен белән абзацтан башлап, әсәрнең исеме, башламы һәм бетеме кебек көчле позицияләренә кадәр – барысы да текст структурасының әһәмиятле компонентлары булып саналалар, шуңа күрә аларны җентекләп, ягъни тел төзелеше һәм әдәби роле ягыннан өйрәнү таләп ителә.

## Әдәби текстның эчке структур үзенчәлеге

Һәрбер язучы иҗат итү процессында әдәби әсәрнең темасын ачу һәм идеясен аңлату өчен иң кулай чараларны куллана. Аларны сайлауда, А.И. Горшков фикеренчә, түбәндәге төп факторлар тәэсир итә: телне куллану шартлары, текстның сүз белән белдерелү формалары, телне куллану төрләре һәм әдәби юнәлешләр[74].

Әдәби әсәрнең ни рәвешле сүздә чагылуы аның төп мәгънәсен ачуга зур йогынты ясый, шуңа күрә бу очракта язучының текст төзү осталыгы ачык чагыла. Аерым алганда, язучылар язмача яки телдән, чәчмә яки тезмә (шигъри), монологик яки диалогик формалардан үзләренә кулай булганын сайлап иҗат итәләр.

**Текстның эчке структурасын** хасил иткән монологик һәм диалогик текстлар дихотомиясен дә тикшерү объекты буларак алдык. Бу төркемгә шулай ук ике каршылыкны берләштереп торган уртак сөйләм дә кертеп карала. Әлеге элементлар авторның үз фикерен белдерү өчен сайлаган чараларны берләштереп бирәләр һәм әсәрнең эчке яки контекстуаль төзелешен оештыралар.

---

[74] Горшков А.И. Русская стилистика. Стилистика текста и функциональная стилистика: учеб. для вузов. – М.: АСТ: Астрель, 2006. – Б. 122-146.

*Монологик һәм диалогик формаларның аермалы яклары*

Монологик һәм диалогик текстларның аермалы якларын түбәндәге катламнарда күзәтергә мөмкин:

*Сөйләм ситуациясенең структурасы* буенча, монологик текст бер зат тарафыннан әйтелгән җөмләләрнең тезелмәсеннән оеша, ә диалогик текст сөйләмдә катнашкан ике яки берничә кешенең әйтелмәләр чиратлашуыннан хасил була.

*Текст оешу закончалыклары* буенча ике форма арасында аерма тагын да ачыграк чагыла. Мәсәлән, тема берлеге ягыннан караганда, диалогик текстларга гадәттә күптемалылык хас, ә монологик текстларда ваграк темалар бердәм гипертема тарафыннан берләштерелеп бирелә.

*Коммуникатив аспекттан* караганда, монологик тексттагы һәрбер җөмлә мәгънәви яктан тәмамланган җөмләләрдән оеша, аларның бөтенесе диярлек аерым тема һәм ремага ия була, тулаем текст төзүдә әһәмиятле роль башкара. Диалогик текстлардагы коммуникатив прогрессияне исә аерым җөмләләр түгел, ә тема белән реманы үз эченә алган сорау-җавап берлекләре тудыра.

*Текстның бердәмлеген оештырган структур күрсәткечләр* ягыннан ике форманы да тематик яктан якын сүзләр, лексик кабатлаулар һәм мәгънәдәш сүзләр (синонимнар) берләштерә. Шул ук вакытта, диалогик текстлар җөмлә төзүдә төп чара булган эллипсис, ягъни әйтеп бетермәү алымын куллану һәм сорау-җавапның синтаксик тәңгәллеге белән аерылып тора.

*Грамматик күрсәткечләр* буенча монологик текстлардагы җөмләләрнең күбесенә хикәяләү формасы хас, ә диалогик текстларда эндәш сүзләр, ымлыклар, үзенчәлекле фигыль формалары, тойгылы, сорау һәм өндәү җөмләләр һ. б. күпләп кулланыла[75].

Димәк, монологик һәм диалогик формаларның охшаш һәм аермалы яклары төрле дәрәҗәләрдә күзәтелә. Әлеге ике төрле текстның һәрберсенә аерым-аерым тукталып, хәзерге татар хикәяләрендә куллану үзенчәлекләрен күзәтү язучыларның һәм

---

[75] Москальская О. И. Грамматика текста. – М.: Высшая школа, 1981. – С. 122-123.

гомумән әлеге чор әдәбиятына хас сыйфатларны ачыкларга ярдәм итә.

*Монологик текстлар*

Тел белемендә һәм әдәбият теориясендә, әйтелү максатына һәм функциональ-мәгънәви үзенчәлекләргә бәйле буларак, монологик форманың 3 төре билгеләнә: хикәяләү, тасвирлау һәм хөкем йөртү.

*Хикәяләү* әдәби әсәрләрдәге вакыйгалар турында сөйләүне аңлата. Бу төр текстларның үзенчәлекләрен хикәя фигыльләрдә кулланылган заманга һәм җөмләләрнең кайсы заттан сөйләүгә карап билгеләргә мөмкин. Гомумән алганда, хикәяләүдә традицион рәвештә хәзерге һәм үткән заман хикәя фигыль киң кулланыла, ә кайсы затны куллану язучының иҗади максатына бәйле сайлана.

*Тасвирлау* – чынбарлык күренешләренең аермалы сыйфатларын, санап чыгу аркылы, сүз белән сурәтләү. Бу фрагментларда пейзаж һәм портретларны тапшыруда телнең кулланылышы тикшерелә, чөнки аларда автор сөйләме ачык чагыла, ә соңгысы, үз чиратында, текст структурасының әһәмиятле өлешен тәшкил итә.

Язучылар портретка, ягъни “кешенең тышкы кыяфәтен, йөз төзелешен, буй-сынын, мимикасын, жестларын, үз-үзен тотышын тасвирлаган тышкы деталь”гә һәрвакыт зур игътибар бирәләр[76]. Портретның ни рәвешле бирелүе әдипләрнең шәхси стиленә, иҗади максатларына, персонажның әсәрдәге роленә бәйле аерылырга мөмкин.

Әдәбият белемендә портретның дүрт төрен аералар[77]:

1. **Сурәтләү портреты** – матур әдәбиятта иң киң таралган гади портрет төре. Ул геройның тышкы кыяфәтен барлык детальләрне кертеп, портретта чагылыш тапкан характер сыйфатларын автор шәрехләве белән җентекләп тасвирлауны күз алдында тота.

---

[76] Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – К.: Мәгариф, 2007. – Б. 139.

[77] Шунда ук. – Б. 139-140.

2. **Портрет-чагыштыру**ның максаты – геройның тышкы кыяфәтендәге детальләрне сурәтләүдән бигрәк, аны укучы күңелендә мәгълүм сурәт белән чагыштырып тергезү.

3. **Портрет-кичереш** – портретның иң катлаулы төре, чөнки монда геройның килеш-килбәтенә, йөз-кыяфәтенә, тышкы детальләргә бөтенләй игътибар бирелми, үзәккә читтән күзәтүчедә яисә әдәби әсәрнең башка персонажында геройның портреты тудырган тойгы куела.

4. **Психологик портрет** – әдипләр тарафыннан шулай ук киң һәм отышлы файдаланылган алым. Ул геройның теге яки бу вакыттагы психологик халәтен, тирән рухи кичерешләрен, күңел тибрәнешләрен тасвирлаганда кулланыла һәм укучы игътибарын геройның тышкы кыяфәтендәге бер детальгә юнәлтү өчен хезмәт итә.

Прозада **пейзаж** фрагментлары да текст структурасында әһәмиятле роль уйныйлар һәм авторның әсәр төзүдәге иҗади максатларына хезмәт итәләр. Портрет белән беррәттән, пейзаж текстның хикәяләү фрагментларындагы тел төзелешен һәм структур үзенчәлекләрен ачыкларга, язучының шәхси стилен аңларга мөмкинлек бирә.

*Хөкем йөртү* фрагментларында исә сүз белән берәр фикерне аңлату, раслау яки кире кагу урын ала, шуңа күрә монда абстракт төшенчәләрне белдергән сүзләр, катлаулы җөмләләр киң кулланыла. Хикәяләү белән тасвирлаудан аермалы буларак, әлеге төр текстлар автор сөйләмендә дә, персонажларның туры сөйләмендә дә чагылырга мөмкин.

Гомумән, монологик текстларда билгеләнгән хикәяләү, тасвирлау, хөкем йөртү фрагментлары әдәби әсәрдә күпчелекне тәшкил итәләр һәм адресатка билгеле бер прагматик тәэсир ясау максаты белән кулланылалар.

*Диалогик текстларның үзенчәлекләре*

Диалогик форма, әдәби әсәрләрдә икенчел урында торса да, проза жанрларында, персонажларның үзенчәлекле сөйләмен тапшыру өчен, бик еш кулланыла. Әлеге төр текстлар үзенчәлекле сүз тәртибе, кыска һәм ким җөмләләр, гади сөйләмә, диалекталь һәм профессиональ лексика һәм фразеологизмнарның киң кулланылуы белән монологик сөйләмнән аерылып торалар. Бу чаралар ярдәмендә

персонажларның сөйләм үзенчәлекләре чагыла, портреты баетыла.

Диалогта сораулар һәм аларга бирелгән җаваплар, репликалар чиратлашуы гына түгел, ә әңгәмәгә катнашучылар да бар, шуңа күрә ул затларга бүленгән текстны хасил итә[78]. Моның аркасында диалог әдәби әсәрнең аерылмас бер өлеше, тулаем текстның катлаулы мозаикасын һәм эчке структурасын төзүдә катнашкан әһәмиятле бер элемент буларак тикшерелергә тиеш.

Рус тел белемендә диалог теориясенә нигез XX гасырның 20-40 елларында ук Л.В. Щерба, Л.П. Якубинский, Г.О. Винокур, В.В. Виноградов, М.М. Бахтин кебек галимнәрнең хезмәтләрендә салына. Алар диалогны сөйләмнең үзенчәлекле формасы, кешенең дөнья белән аралашу чарасы буларак тикшерәләр. Хәзерге вакытта чит илләрдә диалог өч төрле юнәлештә өйрәнелә: “диалогка анализ” (conversation analysis); “сөйләм этнографиясе” (ethnography of speaking); «дискурсанализ» (discourse analysis).

Татар тел белемендә диалогик текстлар М.З. Зәкиев хезмәтләрендә тикшерелә. Аерым алганда, галим диалог, монолог һәм полилогны туры сөйләм кысаларында цитата белән бергә анализлый, аларның автор сөйләме белән мөнәсәбәтләрен һәм төрле очракларның пунктуациядә чагылышын китерә.[79]

Г.Г. Хисамова хәзерге рус тел белемендә диалогның өч аспекттан өйрәнелгәнен искәртә:[80]

1) Структур-семантик яктан, диалог билгеле бер рәвештә оештырылган структура һәм үзенчәлекле сөйләм берәмлеге буларак өйрәнелә. Аның минималь структур берәмлеге булып саналган репликалар мәгънәви һәм синтаксик бәйләнештә торалар.

---

[78] Брудный А.А. Психологическая герменевтика. – М.: Лабиринт, 1998. – С. 107.

[79] Татар грамматикасы. – Том III. – М.: “ИНСАН”, К.: “ФИКЕР”, 1999. – Б. 476-480.

[80] Хисамова Г.Г. Диалог как компонент художественного текста (на материале худож. прозы В.М. Шукшина): автореферат дис. ... док. филол. наук. – Уфа: БГУ, 2009. – С. 9.

2) Функциональ-коммуникатив яктан, диалог сөйләмдә катнашучыларның аралашу гамәлләрен һәм реакцияләрен чагылдыра, шуңа күрә ул кешеләрнең прагматик эшчәнлеге белән тыгыз мөнәсәбәткә керә.

3) Стилистик яктан, әдәби текстгагы композицион-стилистик структураның компоненты буларак, диалог лингвоэстетик анализ объектына әверелә. Сөйләмә телнең табигый яшәү формасы булганга күрә, диалогка иреклелек һәм экспрессивлык хас, ләкин язучыларның сөйләмә элементларны әдәби әсәрдә чагылдыруның никадәр уңышлы икәне тел белемендә әле дә бәхәсле сорау булып кала.

Диалог кешеләрнең сөйләү аркылы тәэсир итүгә нигезләнгән төп аралашу чарасы булып тора. Тел белемендә диалог теориясе актив рәвештә эшкәртелеп килә, ләкин аның бәхәсле моментлары әле дә бар. Диалогка кагылышлы мәсьәләләр катлаулы, шуңа күрә аңа лингвистик анализ ясау өчен культурология, әдәбият белеме, социология, антропология, фәлсәфә кебек арадаш тармакларны да кулланырга кирәк.

Диалог хаклы рәвештә текстның бер элементы булып санала, чөнки анда һәрбер төзек текстка хас булган түбәндәге билгеләр чагыла: катнашучылар санының тотрыклылыгы, ситуация белән үзәккә куелган урын һәм вакыт, репликаларның тел чаралары белән белдерелгән бердәмлеге һәм мәгънәви бәйләнеше.

Диалог һәрвакыт асимметриягә корыла, чөнки аралашуда катнашкан шәхесләрнең активлыгы (сөйләүче роле) һәм пассивлыгы (тыңлаучы роле) алышынып тора. Моннан тыш, диалогтагы хәбәрләр кыска әйтелмәләрдән ирекле рәвештә оешалар, һәр яңа әйтелмә алдагысының тәэсирендә туа. Моның аркасында диалогка әйтеп бетермәү, грамматик форманы кыскарту, мимика һәм ишарәләр куллану, күп тема куллану хас. Бу яклары белән дә диалогик текстлар монологтан аерылып торалар.

Монолог белән диалогтан кимрәк дәрәҗәдә өйрәнелгән полилог төшенчәсе аерым игътибарга лаек. Полилогны аеруда төп критерий – аралашуда катнашкан кешеләр санын икедән артуы, ләкин бу очракта сөйләүче репликасының кемгә һәм нинди чаралар ярдәмендә әйтелгәне аңлашылмаска мөмкин.

Шуңа күрә кайбер галимнәр полилог терминын ике яки берничә яклы диалог төшенчәсе белән алыштыралар[81]. Г.Я. Солганик исә полилогны диалогка каршы куюны хупламый, чөнки аларның икесен дә сөйләүче белән тыңлаучының чиратлашып сөйләве берләштерә[82].

Әдәби әсәрләрдә диалог түбәндәге функцияләрне үти: 1) эстетик-коммуникатив; 2) сюжет оештыру; 3) характерлау; 4) бәя бирү[83]. Бу функцияләр гадәттә үзара керешеп китәләр, шуңа күрә аларны бер-берсеннән аерып тасвирлау мөмкин түгел. Мәсәлән, әсәр геройларының аралашуын һәм үзара тәэсир итүен ачканда, диалог эстетик-коммуникатив һәм сюжет оештыру функцияләрен башкара. Персонаж характерының шәхси һәм типик социаль сыйфатларын тапшырганга күрә, диалогның характерлау һәм бәяләү функцияләре дә зур әһәмияткә ия, чөнки хикәянең төп буыны – характерның асылын ачуга хезмәт иткән вакыйга[84].

Публицистикада һәм мәгълүмати жанрларда диалогның ике төрен аерып тикшерәләр: информатив һәм сюжетлы. *Информатив диалог* стилистик яктан нейтраль, структур яктан гади була, сюжет белән бәйләнешкә керми, мондагы репликалар я турыдан-туры эчтәлекне тулыландыралар, я сорау-җавап берлегенә оешалар. Мондый диалогларны репликаларга бүлмичә дә җиңел сөйләп була.

*Сюжетлы диалог* исә конструктив әһәмияткә ия була, чөнки монда автор репликалар арасындагы (яки  репликалар белән тулаем текст арасындагы) каршылык ярдәмендә “диалогик

---

[81] Макаров М.Л. Диалог с целью принятия решения: опыт дискурсивной психологии. // Жанры речи : Сб. науч. статей. – Саратов: Саратовск. гос. ун-т, 1997.  – С. 153-162.

[82] Солганик Г.Я. Стилистика текста. — М.: Флинта, Наука, 1997. – С. 136.

[83] Хисамова Г.Г. Динамика диалога в рассказах В. М. Шукшина // Вестник Башкирского университета. Т. 14. №3. – 2009. – С. 882.

[84] Хисамова Г.Г. Динамика диалога в рассказах В. М. Шукшина... – С. 884.

киеренкелек” тудырырга омтыла, тасвирланган күренешләрнең драматиклыгын арттыра.[85]

Әдәби әсәрләрдә информатив диалоглар сирәк кулланыла, чөнки монда һәрбер диалог – язучының табышы, персонажның сөйләм үзенчәлекләрен бирү һәм сюжетны башка якка борып җибәрү мөмкинлеге.

Г.Г. Хисамова үзенең монографиясендә В.Шукшин хикәяләрендә кулланылган диалогларны, тапшырылган эчтәлекнең характерына карап, информатив (диалог-сообщение) һәм фатик төргә аерып тикшерә[86]. *Информатив* диалогларда яңа яки кирәкле мәгълүматны тапшыру функциясе өстенлек итә. Монда сөйләүчеләрнең эш-хәрәкәте, халәте, гамәлләре турында хәбәр ителә һәм шулай ук әйләнә-тирәдәге күренешләр турында да сөйләнелә.

*Фатик* диалогның төп максаты мәгълүмат алышу түгел, ә геройларның аралашу ихтыяҗын канәгатьләндерү. Бу төр диалоглар язучыларны персонажның психологик халәтен ачуы, социаль юнәлешле булуы, мәдәни бәйләнешләрне ачыклавы һәм сөйләмнең киеренкелеге белән җәлеп итә. Г.Г. Хисамова В. Шукшин иҗатындагы фатик диалогларда әңгәмә (беседа), бәхәс (спор) һәм талаш (ссора) кебек төрләрнең актив кулланылганын билгели, аларның һәрберсенә хас мәгънәви һәм лингвистик үзенчәлекләрне күрсәтә.

Шулай итеп, төрле формаларда һәм төрле максатлардан чыгып кулланылган диалогик сөйләм әдәби текстның әһәмиятле өлешен тәшкил итә, чөнки аның ярдәмендә персонажларның сөйләм үзенчәлекләре, әйләнә-тирәдәге кешеләргә һәм вакыйгаларга мөнәсәбәте тапшырыла.

*Уртак сөйләм.* Текст теориясендә уртак сөйләм күп еллар дәвамында өйрәнелә, ләкин һәр галим аны үзенчә ачарга омтыла. Галимнәр арасында уртак сөйләмнең урыны турында бәхәс әле дә дәвам итә. Бер төркем телчеләр аны чит сөйләмнең бер төре дип санаса, икенчеләре аны кыек сөйләмгә кертә, ә кайберләре

---

[85] Солганик Г.Я. Стилистика текста. — М.: Флинта, Наука, 1997. – С. 134.

[86] Хисамова Г.Г. Язык современной художественной прозы: диалог в рассказах В. М. Шукшина. – Уфа: БГУ, 2000. – С. 38-54.

автор белән персонаж сөйләмнәренең кушылуыннан барлыкка килгән махсус стилистик алым дип бәяли. Мәсәлән, Л. А. Соколова уртак сөйләмне стилистик категория буларак махсус тикшерә һәм автор белән геройның субъектив планнарын үзара берләштерүгә нигезләнеп барлыкка килгәнен ассызыклый[87]. И. И. Ковтунова фикеренчә дә, уртак сөйләм – авторның хикәяләве белән персонажның эчке сөйләм элементларын берләштерүгә һәм үзара катнаштыруга нигезләнгән стилистик алым[88]. Ф. С. Сафиуллина уртак сөйләмне текст категориясенә кертеп караса[89], И. Р. Гальперин аны контекст-вариатив бүленеш кысаларында автор һәм персонаж сөйләм актларыннан аерым тикшерә[90].

Монологик һәм диалогик форма мөнәсәбәтеннән караганда, эчке структураның бер элементы булып торган уртак сөйләмне беренче төргә кертү дөресрәк, чөнки аның эчендә монологик текстларга хас җөмлә төзелеше, ритм һәм стиль үзенчәлекләре өстенлек ала. Шул ук вакытта әлеге төр сөйләмдә персонажларның шәхси тел үзенчәлекләре дә ачык чагыла, шуңа күрә ул еш кына диалогик сөйләмгә хас сыйфатлар белән баетыла.

Уртак сөйләм әдәбиятның, аеруча прозаның үсеш дәрәҗәсен күрсәтә торган алым булып санала, чөнки аны куллану өчен автордан персонаж булып хисләнә һәм фикер йөртә алу, ягъни герой образына керә алу һәм аның тирән психологиясен аңлап тапшыру осталыгы таләп ителә. Рус әдәбиятында уртак сөйләм XIX гасыр башында ук кулланыла башлый, ә татар әдәбиятында XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында иҗат ителгән З. Һади, Р. Фәхретдин, Ш. Мөхәммәдев

---

[87] Соколова Л.А. Несобственно-авторская (несобственно-прямая) речь как стилистическая категория. — Томск: Изд-во Томск. ун-та, 1968. – С. 22.

[88] Ковтунова И.И. Несобственно-прямая речь в языке русской литературы конца XVIII – пер. пол. XIX в. Рукопись канд. дисс. - М., 1955. – С. 111.

[89] Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. – Б. 125.

[90] Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. – М.: Комкнига, 2007. – С. 25

һ. б. чәчмә әсәрләрендә күзәтелә. Алга таба Ф. Әмирхан, Ш. Камал әсәрләрендә уңышлы үстерелгән әлеге алым 60-70 еллар татар прозасында – Ә. Еники, Ф. Хөсни, М. Мәһдиев, Р.Төхфәтуллин һ. б. язучыларның иҗатларында аеруча киң һәм уңышлы кулланыла.

Татар тел белемендә уртак сөйләм чагыштырмача соңрак – Х.Р. Курбатов хезмәтләрендә генә тикшерелә башлый, әлеге күренешнең терминын да ул тәкъдим итә[91]. Алга таба уртак сөйләмне өйрәнү М. З. Зәкиев, Ф. С. Сафиуллина хезмәтләрендә дәвам иттерелә, аның төп үзенчәлекләре һәм әдәби әсәрләрдә ни рәвешле кулланылуы билгеләнә.

Автор һәм персонаж арасында торганга, уртак сөйләмнең адресатка тәэсире туры сөйләмгә караганда күпкә көчлерәк. Кайбер телчеләр, мәсәлән, Л. А. Соколова, аны эчтәлеге (автор һәм геройның субъектив планнарын берләштерүе аркасында) һәм белдерелү чаралары ягыннан (гомуми автор контексты белән аеруы яки берләштерүе аркасында) автор һәм персонаж сөйләме белән беррәттән торган өченче мөстәкыйль категория дип саный[92].

Тел белемендә уртак сөйләмне куллануның төрле сәбәп-ләрен билгелиләр: 1) герой үзенең фикерләрен оештырып бирә алмаганга күрә, моны герой исеменнән автор эшли; 2) стилистик яктан төрләндерү кирәк була; 3) диалогның үзенчәлекле төзелешен күрсәтергә кирәк була; 4) теге яки бу күренешкә басым ясау ихтыяҗы туа; 5) монологик һәм диалогик сөйләм арасында чикләрне югалту кирәк булырга мөмкин; 6) башка хикәяләү формаларының функцияләре артып киткәндә, автор уртак сөйләмгә мөрәҗәгать итә; 7) синомимик алмаштыру чарасы булмаганда, уртак сөйләм килеп керә.[93]

---

[91] Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби телендә туры, кыек һәм уртак сөйләмнәр: Филология фән. канд... дис.. – К., 1953. – 341 б.

[92] Соколова Л.А. Несобственно-авторская (несобственно-прямая) речь как стилистическая категория. — Томск: Изд-во Томск. ун-та, 1968. – С. 22.

[93] Соколова Л.А. Несобственно-авторская (несобственно-прямая) речь как стилистическая категория. — Томск: Изд-во Томск. ун-та, 1968. – Б. 274.

Уртак сөйләмне әсәр тукымасыннан аерып чыгару кайвакыт билгеле авырлыклар тудыра, ләкин күрсәткечләрен дөрес билгеләгән очракта аның ни рәвешле формалаштырылганы һәм лингвистик үзенчәлекләре ачыклана. Уртак сөйләмнең аермалы билгеләрен галимнәр төрлечә төркемләп бирәләр.[94]

Мәсәлән, Л.А. Соколова үзенең хезмәтендә уртак сөйләмнең аермалы билгеләрен автор сөйләменә мөнәсәбәттә тикшерә һәм белдерелү чараларының шактый төзек системасын тәкъдим итә. Әлеге система эчендә уртак сөйләмне әсәр контекстына кертүгә яки автор хикәяләвеннән аерып чыгаруга хезмәт иткән, я ике функцияне дә берьюлы башкарган чаралар җыелмасы берләш-терелеп тикшерелә.[95] Шактый уйланылган булуга карамастан, әлеге бүленештә кайбер кабатлаулар очрый, шуның аркасында ул артык киңәя һәм катлаулана.

Уртак сөйләмне хәзерге чор рус анималистик прозасына таянып өйрәнгән Е. Е. Беличенко үзенең диссертациясендә аның лингвистик билгеләрен 3 катламга җыеп бирә:

1. *Грамматик-морфологик* билгеләр заман, юнәлеш, зат һәм коммуникатив регистр кебек категорияләр белән тыгыз бәйләнгән. Автор сөйләменә ишарә итә торган абсолют мәгънәле заман кулланылган җөмләләрдән мөнәсәбәтле заманга күчеш ачык сиземләнә. Уртак сөйләмдә заман формасын сайлау персонаж модусы белән билгеләнә (искә төшерү, хөкем йөртү модусы һ. б.). Ә затның үзгәрүе өченче заттагы алмашлыкның беренче зат мәгънәсендә кулланылуында күренә.

2. *Синтаксик* билгеләргә уртак сөйләмнең синтаксик структурасын кертергә мөмкин. Уртак сөйләмнең күләме бер җөмләдән алып, берничә абзацка сузылган җәенке хәбәрләмәгә җитә ала. Пунктуация уртак сөйләмне билгеләүдә аеруча зур роль уйный, кайвакыт автор сөйләменнән аерып торган бердәнбер күрсәткеч (маркер) булып тора. Ләкин гомумән

---

[94] Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. – Б. 131-135.

[95] Соколова Л.А. Несобственно-авторская (несобственно-прямая) речь как стилистическая категория. — Томск: Изд-во Томск. ун-та, 1968. – Б. 42.

алганда, әдәби әсәрләрдә уртак сөйләмне график яктан мөмкин кадәр белдермәү тенденциясе күзәтелә. Синтаксик билгеләргә экспрессив синтаксисның төрле чаралары да кертеп карала: сорау, өндәү (еш кына номинатив һәм инфинитив) җөмләләр, сорау-җавап комплекслары, эллипсис һәм парцелляция. Алар персонажның эмоциональ реакциясен күрсәтәләр һәм әсәрдә сөйләшү хисен тудыралар. Кабатлаулар ярдәмендә исә турыдан-туры персонажның кабул итүе чагыла, димәк, аның субъектив планына ишарә ителә.

3. *Лексик* билгеләргә, стилистик бизәлгән сүзләрдән тыш, сөйләшкән затка ишарә иткән һәм аның хәбәрләмәгә мөнәсәбәтен белдергән эгоцентрик тел элементлары да кертеп карала: 1) әнә, менә, бу кебек күрсәтү алмашлыклары, ымлыклар; 2) метатекст элементлары; 3) эчке халәт предикатлары, шул исәптән кайбер кереш сүзләрнең төрләре; 4) билгесезлек алмашлыклары һәм рәвешләр; 5) охшашлык һәм тәңгәллек предикатлары; 6) идентификация күрсәткечләре: 7) кискенлек мәгънәсенә ия сүзләр; 8) гомумиләштерүче “кисемтәләр”; 9) бәяләү мәгънәсенә ия сүзләр; 10) объект номинацияләре.[96]

Е.Е. Беличенко билгеләгән лингвистик үзенчәлекләр конкрет материалга бәйле рәвештә бирелүе һәм төгәллеге, анализ өчен уңайлы булуы белән аерылып тора. Ләкин беренче төркемне морфологик дип калдыру, безнеңчә, кулайрак, чөнки грамматика үз эченә морфология белән синтаксисны да ала.

Язучының осталыгына һәм әсәрдә куллануның максатына карап, уртак сөйләмнең әдәбиятта төрле типлары бүлеп чыгарыла. Аларның төгәл классификациясен төзү шактый катлаулы, ләкин текст теориясенә һәм лингвостилистик анализга багышланган хезмәтләрдә әлеге бүленешнең төрле вариантларын табырга мөмкин.

Мәсәлән, Е. Е. Беличенко, структур-семантик принципка нигезләнеп, уртак сөйләмнең 6 формаль тибын күрсәтә:

---

[96] Беличенко Е.Е. Несобственно-прямая речь в языке художественной литературы (на материале анималистичекой прозы): автореферат дис. ... канд. фил. н. – СПб: Изд-во СПбГУ, 2006. – С. 16-19.

*Персональ* уртак сөйләм туры сөйләм белән охшаш була, ләкин тыныш билгеләреннән башка бирелә һәм функциональ бизәкле лексика белән аерыла. Монда сорау, өндәү, инфинитив һәм семантик субъекты төшеп калган җөмләләр кулланыла. Хикәяләү III заттан барганда персонажның I заттан сөйләве дә бу төргә керә.

*Арадашчы* уртак сөйләм кыек сөйләмгә махсус фигыль формасы, ияртүче бәйләнеш, вакыт белән затның транспозициясе, дейксис элементларын куллануы белән охшаш. Әлеге төр уртак сөйләм ярдәмендә, актның төре алдан ук белдерелеп, персонажның менталь, перцептив яки вербаль акты тапшырыла.

*Лексик-семантик* уртак сөйләм автор хикәяләвеннән персонажга хас лексик-фразеологик берәмлекләргә бай булуы белән аерылып тора. Аның эчтәлеге бары тик персонаж позициясенә генә туры килә.

*Семантик* уртак сөйләмдә персонажның менталь, перцептив яки вербаль акты төре аталмыйча гына тапшырыла, автор контекстыннан килеп чыга, ләкин лексикасы белән хикәяләүдән аерылмый. Монда төп рольне мәгънәви критерий уйный.

*Авторлаштырылган* уртак сөйләм автор контекстыннан аерылып тормый диярлек.

*Цитаталы* уртак сөйләм тиешле тыныш билгеләре белән яки берникадәр яшереп бирелә һәм бик сирәк кулланыла.[97]

Әлеге классификация, тотрыклы һәм җыйнак булуга карамастан, уртак сөйләмнең барлык төрләрен төгәл биреп бетерми. Моның төп сәбәбе – кыскалыкны саклау белән бергәттән берничә төр принципны кушырга омтылу. Шуңа күрә без өйрәнелгән материалда күзәтелгән мисалларны Л.А. Соколованың автор белән персонаж сөйләме арасындагы мөнәсәбәткә, аларның мәгънәви үзенчәлекләренә таянган

[97] Беличенко Е.Е. Несобственно-прямая речь в языке художественной литературы (на материале анималистичекой прозы): автореферат дис. ... канд. фил. н. – СПб: Изд-во СПбГУ, 2006. – Б. 19-21.

классификациясенә[98] нигезләнеп гомумиләштерергә булдык. Галимә уртак сөйләмне дүрт критерий буенча аерырга тәкъдим итә:

– автор белән геройның бер-берсенә тәэсир итү дәрәҗәсенә,

– тапшырылган күләмгә,

– хикәяләүне алып баручы автор яки аны алыштырган хикәяләүченең (автор образының) роленә һәм

– кемнең фикерен белдерүенә (геройның кыяфәтенә) бәйле рәвештә.

Шулай итеп, уртак сөйләмнең төрле типлары әдәби әсәрләрдә персонажның үзенчәлекле фикерен һәм авторның мөнәсәбәтен бирү өчен киң кулланылганы ачыкланды. Шул ук вакытта, күптәннән өйрәнелгән булуына карамастан, әлеге әдәби алымның барлык үзенчәлекләре дә ачылмаганы, бер принципка нигезләнгән тотрыклы бүленешнең юклыгы күзәтелә.

## Когезия

Тасвирлана торган күренешләр арасында һәрвакыт ниндидер бәйләнешләр була. Алар грамматик бәйләнеш чаралары белән генә белдерелмичә, башка төрле юллар белән дә формалашалар. Текстның аерым кисәкләре, бер-берсеннән ерак урнашсалар да, үзара бәйләнештә булып, континуум барлыкка китерә торган үзенчәлекле чаралар *когезия* дип аталалар. Когезия төрле чаралар белән белдерелә ала. Текстны оештыручы традицион грамматик чаралардан тыш, логик, ассоциатив, образлы, композицион-струк-тур, стилистик һәм ритм оештыручы чаралар була. Традицион-грамматик чараларга теркәгечләр, теркәгеч сүзләр, алмашлыклар, хәл фигыльле, сыйфат фигыльле әйләнмәләрне кертергә мөмкин. Алар аерым җөмләләр арасындагы бәйләнешләрне белдерәләр, шул ук вакытта алар синтаксик бөтеннәрне оештыруда, бәйләүдә дә катнашалар.

---

[98] Соколова Л.А. Несобственно-авторская (несобственно-прямая) речь как стилистическая категория. — Томск: Изд-во Томск. ун-та, 1968. – Б. 24-34.

Вакыт-урын рәвешләре *әле, тиздән, каршында, еракта, якында, ерак, түгел* җөмләләр арасында вакыт-урын мөнәсәбәтен белдерәләр.

Когезия санау формалары (беренчедән, икенчедән..., график чаралар а) ә) б); 1), 2), 3) белән белдерелә, мәсәлән, фәнни стильдән бер мисал: Х. Р. Курбатовның «Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы» дигән китапта фразеологиянең стилистик куллануның төрләре саналып бирелә: 1) фразеологизмның, бер кисәген алыштыру; 2) әзер үрнәк буенча яңа фразеологизм ясау; 3) фразеологик әйләнмәне ирекле сүз тезмәсе хәленә кайтару; 4). фразеологик омоним ясау һ. б. Шул рәвешле 9 пункт саналып кителә. Бу чаралар эзлеклелек, вакыт, урын, сәбәп максат мәгънәләрен белдерәләр һәм бу логик чараларда грамматик һәм текстка хас бәйләнеш формалары кисешә дә инде.

Ассоциатив когезияне тою җиңел түгел. Кайчак «исенә төшерде», «шуңа охшаш», «уй йөгерде», «хатирәләргә чумды» һ.б. кебек сүзтезмәләр дә мондый бәйләнешләрне белдерәләр.

Әдәби әсәрдәге ассоциацияләр аны язу, иҗат итү процессының нәтиҗәсе буларак барлыкка киләләр. Лирик шигырьләрдә бу бигрәк тә ачык чагыла. Мәсәлән, сүзләр арасында тышкы бәйләнеш (охшашлык) эчке бәйләнеш иллюзиясен тудырырга мөмкин. Тел белемендә *паронимик аттракция* дип атала.

Образлы когезиянең бер төренә җәенке метафораны да кертеп карыйлар.

Когезиянең композицион-структур төрләренә караган чаралар хикәяләүдәге эзлеклелекне һәм логик оешканлыкны төрле керешмәлор, чигенешләр, күренешләрне вакыт һәм урын ягыннан сурәтләүләр белән өзеп куялар; үз чиратында алар хикәяләүнең төп сюжетына гурыдан-туры бәйләнмәгәннәр. Болар – хикәяләүнең икенче планы. Матур әдәбият әсәрләрендә, гомумән, логик эзлеклелекне табу мөмкин түгел. Вакыйгалар урын һәм вакыт ягыннан гаять төрле рәвештә кисешкән, буталган булалар. Тормыш үзе тәртипсез, очраклы, алдан программалаштырылмаган, өзелгән күренешләрдән, вакыйгалардан гыйбарәт. Әдәби әсәр тормышны чагылдырганга күрә, андагы вакыйгалар да тормыштагыча сурәтләнәләр.

Когезиянең стилистик һәм ритм оештыручы формалары үзара үрелеп бара. Боларга һәр синтаксик бөтеннең бертөрлерәк оешуы, хиазма, бер үк стилистик алымның кабатлануы кебек чараларны кертергә мөмкин. Ә. Еники «Төнге тамчылар» хикәясендә Ләйлә туташны тасвирлаганда аны ак күбәләк белән чагыштыра: «Кызның исеме Ләйлә иде. Гаҗәп, кайчагында кешенең исеме үзенә ничектер бик туры килеп, бик килешеп тора. Гүя менә бу кыз да *ак күбәләк* кебек нәфис, җиңел, нечкә җанлы булганга күрә Ләйлә исемле иде, Ләйләдән башка бүтән бер исем дә аңа һич туры килмәс кебек иде. һәм, әйтерсең, *ак күбәләккә* охшаганга күрә дә аңардан чәчәкләр дөньясына хас табигый садәлек, назлы-нәфис сөйкемлелек аңкып тора иде». Икенче тапкыр бу сүзтезмә болай килеп керә: «Хәзер инде Хәлил шул *ак күбәләкнең* нечкә мәхәббәтен куркытмыйча сак кына ике учына алырга тиеш иде». Алга таба Ләйлә, Хәлилнең хыянәтен күтәрә алмыйча Ленинградка китеп бара: «Аныңниләр кичереп, нинди хәлдә китүен Хәлил күз алдына китерергә дә курка иде. *Ак күбәләк,* әйтерсең, кара мунча тирәсеннән иркен кырга очты...» Әмма *«ак күбәләк»* Хәлил күңелендә һаман яши бирә: «Тик Хәлил үткәннәрне бик йөрәк кенә исенә төшергән минутларда *ак күбәләк* шул яшеренгән урыныннан гүя терелеп чыга иде дә., кунарга чәчәк эзләгәндәй, лпың хыял күгендә тын гына талпына башлый иде». Ләйләнең кайту хәбәрен ишеткәч, Хәлил күңелендә Ләйлә ханымны күрү теләге уяна: «Ниндирәк икән ул? Кайчандыр *күбәләктәй* җиңел-сылу кыз, хәзер инде кырыктан узган хатын булгач, нинди кыяфәткә керде икән?..» Язгы тамчылар тавышын ишеткән Хәлил күзләрен ачып әйтә: «Йа хода, яз ич бу, яз! Ләйлә ич бу, Ләйлә! Тамчылар шуны тукыйлар бит аңа: *ак күбәләгең* яз булып, яшәрү булып, яңару булып кайтты, диләр сиңа!..» Соңгы тапкыр *ак күбәләк* тезмәсе *аккош* белән алышына: «Хәзер аны гамьсез ак күбәләккә түгел, ә горур аккошка охшатырга мөмкин булыр иде». Шул рәвешле, *ак күбәләк* тезмәсе, әсәрнең буеннан буена килеп, билгеле бер образ барлыкка китерә.

Когезиянең ритм барлыкка китерә торган формалары, нигездә, шигъри әсәрләрдә дә күзәтелә; шул ук вакытта прозаның да үз ритмы була.

## Континуум

Текст теориясендә континуум вакыт һәм урын төшенчәләре белән турыдан-туры бәйләнгән. Термин үзе өзлексез барган үзгәрешләрне чагылдыра. Текстта континуум фактлар, вакыйгалар, күренешләрнең урын һәм вакыт ягыннан үсешен, җәелүен белдерә[99]. Урын һәм вакыт төрле текстларда төрлечә чагылыш таба. Матур әдәбиятта реаль вакыйгалар түгел, бар дип уйланган вакыгалар сурәтләнә. Вакыйгалар вакытның эзлекле агышында гына сурәтләнмиләр: хәзерге заман хикәяләвенә элек булган вакыйгалар да килеп керә. Мәсәлән, М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә», "Бәхилләшү» әсәрләрен алырга мөмкин. Аларда хикәяүче автор образы хәзерге заман яссылыгында сурәтләнә, хатирәләр рәвешендә бирелгән материал үткән заманда сурәтләнә. Бу ике план бер-берсен алыштырып, чиратлашып киләләр.

Әдәби әсәрдә континуум тасвирлауны конкретлаштыра, аның тормышчан булуын тәэмин итә. Әдәби әсәрдәге урын вакытка караганда конкретрак билгеләнгән була. Вакыт төшенчәсе аерым бер конкрет сүзлә исәбенә, фигыль заманнарына бәйле рәвештә тасвирлана, ләкин укучы, вакыт үткән заман фигыльләр белән белдерелсә дә, күп очракта вакыйгаларны хәзерге заман итеп кабул итә.

Континуум җөмләдә түгел, текстта барлыкка килә һәм бу процесста фигыль заманнарының, аларның үзара мәгънәви функциональ бәйләнешләренең роле гаять зур була[100]. Үткән заман киләчәк заманга караганда аңлаешлырак: үткән заман мәгълүм, узган хәлләрне белдергәнгә күрә борчу уятмый. Әдәби әсәрдәге үткән заман безгә якынайтыла: автор үткәнне хәзерге заман ясый һәм укучы шуларны күрә ала.

Текстта төрле заман формалары бер-берсен алыштырып килә алалар: хәзерге заман үткән заманны белдерә һәм киресенчә. Кайбер фигыль формаларын, мәсәлән *-а иде*

---

[99] Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – Б. 68.
[100] Шунда ук. – Б. 68.

формасын даими эшләрне белдерә торган заманга тартым дип тә була.

Әдәби әсәрдә вакыт эзлеклелеге тасвирлау, диалог, авторның лирик уйланулары белән өзелеп тә торырга мөмкин. Монда иакыт тукталып калгандай була. Шулай да вакыт хәрәкәте һәм урынның алмашынуы юкка чыкмыйча, арткы планга гына күчә. Күп телләрдә хәзерге заман иң гомуми заманнардан санала, чөнки ул үткәнгә дә, киләчәккә дә юнәлтелгән. Аның төрле мәгънәләре бар: сөйләм белән бер вакытта үтәлгән эш; гадәти, типик яисә кабатлаулы эш; узуаль эш; затның даими эше; заманга бәйсез эш; сөйләмнән соң булган эш; төрле модаль мәгънәләр өстәлгән эш; императив, башка эш өчен шарт булган эш. Мондый күп мәгънәләре булу хәзерге заманны төрле ситуацияләрдә һәм төрле эстетик-әдәби максатларда кулланырга мөмкинлек бирә. Континуум өчен фигыльләрнең җөмлә эчендәге түгел, ә синтаксик бөтеннәрдә алган мәгънәләре әһәмиятлерәк. Текст дәрәҗәсендә фигыльләләрнең мәгънәләре, заман төсмерләре нейтральләшә[101].

Әдаби әсәрдә вакыйгалар күбрәк урынга беркетелгән булалар, ә вакыт ул хәтле үк конкрет булмаска да мөмкин. Әмма хәзерге заман укучыга гаять якын, ул барлык картиналарны сурәтләүдә катнаша, безне вакыйгалар барган вакытка күчерә. Укучы вакыйгаларны ике планда – реаль һәм ирреаль планда кабул итә. Укучы шушы ике планны һәрвакыт аңлап эш итә һәм континуум, вакыйгаларның гади эзлеклелеген генә түгел, аларның үзара төрлечә бәйләнешен дә билгеләргә ярдәм игә.

## Тексттагы ретроспекция һәм проспекция

Текстның алга таба үстерелешендә ретроспекция һәм проспекция зур роль уйный. Вакыт һәм урын-ара мөнәсәбәтләр белән алар гаять тыгыз бәйләнгәннәр. Алар текст үстерелешендә бер «тын алу» кебек тоелалар. Шулар аша гына үткән вакыйгаларны аңлау мөмкин. Галимнәр төрле телләрдә үткән

[101] Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. – Москва: Наука, 1981. – С. 44.

заманның формалары күп булуны хәтта универсаль бер күренеш дип санаганнар.

Күпчелек текстларда ретроспекция имплицит рәвештә - сүз белән махсус әйтелмичә белдерелә.

Безнең хәтеребездә элек әйтелгәннәр саклана һәм шулар яңа өзекләр белән бәйләнешкә керәләр. Укучы булачак вакыйгалар турында уйланганда да аның юнәлешен билгели ала. Димәк, проспекциядә – сөйләнә торган вакыйгаларның киләчәккә таба юнәлтелгән булуы – имплицит рәвештә сурәтләнә ала.

Ретроспекция һәм проспекция текст категорияләре дип саналалар, чөнки алар бер җөмлә эчендә генә белдерелә алмыйлар, ә текст эчендә реализацияләнәләр.

Ретроспекция – укучыны алдагы эчтәлеккә юнәлтә торган, тексттагы тел тәгъбирләрен берләштергән грамматик категория. Ул ике төрле ачыклана: 1) алдагы мәгълүмат инде текстта әйтелгән була; 2) мәгълүматта текстның алга таба хәрәкәте өзеп әйтелә, хикәяләүнең вакыт планы күчерелә[102].

Автор ретроспекциягә зур игътибар бирә. Ул әледән-әле алда әйтелгән вакыйгаларны искә төшерә, аларның төрле якларын кабатлап-кабатлап ала, укучыдан аларга игътибар итүне сораган кебек була.

Ретроспекция текстта нинди прагматик максат ятуга бәйле өч төрле була:

1) укучы хәтерендә элек әйтелгәннәрне торгызу, аларны булачак хикәяләүне аңлау өчен җирлек хәзерләү;

2) бу мәгълүматларны яңа шартларда, яңа контекстта уйлап карау өчен мөмкинлек бирү;

3) текстның эчтәлегендәге аерым кисәкләрне актуальләштерү.

Димәк, ретроспекция текстның, аерым кисәкләрен яңадан мәгънәви ассызыклап карап чыгу өчен кирәк була. Ретроспекция, әсәрне яңадан укыганда, аеруча нәтиҗәле кабул ителә.

---

[102] Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. – Москва: Наука, 1981. – С. 88.

Теләсә кайсы текст ретроспекциягә нигезләнә. Мәгълүмат туплану элек укыганнарга бәйле була. Автор аны махсус та эшли, аерым фактларны укучының хәтеренә һаман төшереп тора.

Укучы тарафыннан барлыкка китерелсә, ретроспекция – субъектив, ә автор; тарафыннан үткән вакыйгаларга тел чаралары белән ишарә ителсә, объектив-иҗади төс ала. Укучы хикәяләү дәвамында элек укылган төрле-төрле вакыйгаларны исенә төшерә, аларны бәйли. Субъектив ретроспекция хикәяләүнең аерым өлешләрен үзара бәйли торган интеграция категориясенә бәйле була. Элек укылганга кире кайту текст композициясенең нәтиҗәсе булып тора. Әгәр текстта *исенә төшерде, хатирәләргә чумды, укучы хәтерлидер, хәтеренә төште* һ.б. тәгъбирләр очраса, авторның объектив ретроспекциясе башлана дигән сүз.

Ретроспекция төрле чаралар белән белдерелә. Шулардан иң еш кулланыла торганы дип кабатлауны санарга кирәк. Ретроспекция үзе дә кабатлауның бер төрле – фикер кабатлаулары дип санала ала.

Ретроспекция әсәрнең заман катламнарын куша: текстны үткән, хәзерге һәм киләчәк заман күзлегеннән карарга мөмкинлек туа.

Ретроспекция, текстның башка грамматик категорияләре кебек үк, когезия, информативлык, автосемантия, кисәкләргә бүленү һ.б. тыгыз бәйләнгән.

Бу категориянең тормышка ашуы укучының эчтәлекле – копцептуаль хәбәрне кабул итүгә әзерлегенә бәйле.

Мондый мәгълүматны җиңел генә аңлау мөмкин түгел, Укучыдан югары зәвык, әдәби сурәтләү кануннарын, стилистик алымнарны, композициянең төзелеш калыпларын аңлау, югары культура таләп ителә[103].

Әсәрне яңадан, кабат укымый торып, ретроспекцияне аңлау шактый кыен. Шуңа күрә кайта-кайта укыганда гына, әдәби әсәрдән автор язганга адекват диярлек хәбәр алырга

---

[103] Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – Б. 78.

мөмкин. Ретроспекция тексттагы аерым өлешләрнең үзара бәйләнешен булдырып, интеграция процессын тәэмин итә.

Теге яки бу текстны аңлау – андагы мәгълүматны аңлау дигән сүз. Мәгълүмат текстның аерым кисәкләрендә бирелә; алар текстта төрлечә урнашалар. Укучы аларны сайлап ала, хәтерендә калдыра. Тексттагы мәгълүматны аңлау өчен, кисәкләренең урнашуы һәм алар арасындагы бәйләнешләрне ныклап өйрәнергә кирәк; ә бу инде ретроспекциягә алып. килә. Текст кисәкләре үзара ничек урнашуның, әһәмияте авторның идеясеннән читкә китә алмый. Без аны бары шушы контекстта гына кабул итәбез. Мәсәлән, Ә. Еникинең «Җиз кыңгырау» әсәре болай башланып китә: «Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез җиз кыңгырау тора. Кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка барган чагында ул кара дугага тагылган килеш, ат башында йөри иде. Хәзер кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та юк, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә менә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган. Әллә нигә бер мин аны кулыма алып, әкрен генә селкеп карыйм. Җиз кыңгырау шунда ук телгә килгәндәй, дәртле тавышын чыгара: «Зың-зиң, зың-зиң!..» Нәкъ менә кара дугада чактагы шикелле чыңлап, яңгырап китә. Гаҗәп, вакыт дигәнең дә көчсез икән бу җиз кыңгырау алдында, вакыт аны әз генә дә, ичмасам, үзгәртә алмаган. Ул элеккечә яшь, дәртле, моңлы һәм нindidер бер могҗиза белән мине күз ачып йомганчы кырык ел артка, яшүсмер чагыма күчерә дә куя».

Шул юллардан соң ике өзекне аера торган билгеләр куела һәм әдип яшьлек хатирәсен сөйли. Бу хатирәдә алда әйтелгән җиз кыңгырау, кара дуга белән җигелгән озын яллы сары ат, атның хуҗасы Нигъмәтулла абзыкай турында сөйләнә, Абзаң авылына туйга бару хатирәсе хикәяләнә. Алда тасвирлама башламдагы кыңгырау тагын кабатланачак әле: «...ерактан, ап-ак арыш кырлары түреннән «зиц-зин,» чыңлаган кыңгырау тавышлары ишетелде. Бу тавыш ерак һәм әкрен булса да, капка төбендә торучы бер егет яман кычкырып җибәрде:

– Туй килә-ә!

Әйе, туй килә, туй! Бар да капкага ташландылар. Мин дә урамга йөгереп чыктым. Ләкин атлар күренмиләр иде әле, тик

кыңгырау тавышлары гына отыры дәртләнебрәк, ашыгыбрак ядгырый-көчәя бара иде...»

Хикәмләү дәвам итә. Менә туйга кияү егетләре белән кияү килә: «Атларны бик көязләп җиккәннәр – ялларына ал, кызыл тасмалар үрелгән, калын кара дугада куш кыңгырау, тәңкәле йөгән, тәңкәле эшлия, эшлиянең каеш чуклары ике яктан асылынып тора...»

Кыңгырау тавышы тагын кабатланачак әле. Хикәяләүче яшүсмер Әхтәм хуш исле печәнлектә ятканда, тагын кыңгырау тавышы ишетә: «...нечкә кыңгырау тавышына кушылып, кызлар көлүе ишетелде, ул да булмый, сыздырып гармун уйнап җибәрде. Әнә нәрсә икән ул. Кияү егетләре, пар атларына ястыкчы кызларны утыртып, урам әйләнәләр...»

Укучы, кыңгырау моңы белән тагын бер очрашачак әле. Туй китү күренешен әдип менә болай тасвирлый:

Кияү атлары урамга чыккач, туй кузгалды... Дәррәү кузгалып киткән атларның кыңгырау, тавышлары кечкенә авылны тәмам күмеп, бөтен Түреш буйларын яңгыратып җибәрде, Әйе, бу искиткеч бер тамаша иде. Капка тибендә өелешеп калган егетләр һәм кызлар ераклаша барган кыңгырау тавышларын сихерләнеп, онытылып, шылт та итмичә тыңлан тордылар. Туй китте. Туй белән бергә кемнеңдер яшьлеге китте... Тагын кемнәргә насыйп булыр икән бу кыңгырау тавышлары?!

Алда сурәтләнгән вакыйгалар – авторның хатирәләре, алар хикәяләүнең үзәген, ретроспекцияне тәшкил итәләр.

График билгеләрдән соң яңа абзац башлана: бусы әдипнең бүгенге көне, ул безне хәзерге заманга кайтара. Китаплар шүрлегендә торган җиз кыңгырау туйга барган атның дугасына тагылып барган булган икән, шуның истәлеге икән... Вакыйгаларга катнашкан кешеләрнең күбесе дөньяда юк икән инде, килен белән кияү үзләре дә әби белән бабай булганнар инде. Гадәтләр дә үзгәргән... «Әйе, дөньяда бөтен нәрсә искерә, туза, үзгәрә, тик менә җиз кыңгырау, ни хикмәттер, һич кенә дә бер үзгәрми. Чак кына кагылдың исә, нәкъ теге вакыттагы шикелле, көмештәй саф, нечкә, дәртле тавышы белән бүлмәне яңгыратып җибәрә (...)

Әмма мәңге үзгәрми торган бер нәрсә калды: бу – кешенең яшьлеге, кешенең мәхәббәте! Һәркемгә килә ул, һәркем кичерә аны... Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа – аның дәртле, көмеш тавышында гүя яшьлек һәм мәхәббәт) саклана».

Әдәби әсәрдә кайчак аерым детальләр күзгә ташлана һәм алар теге яки бу мәгънәне ачар өчен хезмәт, итә башлыйлар. Детальләр төрлечә ераклыкта, төрле ситуацияләрдә кабатланалар.

Ретроспекция континуум белән тыгыз бәйләнгән. Хикәяләүдәге өзеклек авторның уйланулары, хикәяләү яссылыгының алышынуы проспекция һәм ретроспекцияләрдә чагылыш таба.

Ретроспекцияне тәэмин итүче чаралардан *дейксис* категориясен күрсәтеп үтәргә кирәк. Дейксис – киң мәгънәдә нәрсәгә булса да күрсәтү дигән сүз[104]. Күрсәтү алмашлыклары, эшнең юнәлешен белдерүче кайбер рәвешләр, фигыльләрне дә дейксиска кертеп карарга мөмкин. Мәсәлән: югарыда, әйтелгәнчә, кайчандыр, югарыда күрсәтелгәнчә, без ул турыда алда әйткән идек инде, искә төшерик, аның исенә төште һ.б. Болар фәнни һәм рәсми стильдә, матур әдәбиятта аеруча күп. Кино сәнгатендә дә ретроспектив кадрлар табигый күренә..

Бу дейктик чаралар бөтен бер текстның аерым кисәкләре арасындагы бәйләнешне аңлауны җиңеләйтәләр һәм бу бәйләнешләрне автор күргәнчә ачыкларга мөмиинлек бирәләр.

Ретроспекциягә бәйле тагын бер күренешкә тукталыйк. Бу – соңгы сүз, йомгак, эпилог. Укучы төп вакыйгалар, күренешләр, факторларны карап килеп, йомгакта туларның асылын күрә. Йомгакның төрләре гаять күп булырга мөмкин. Кайберләрендә текстта әйтелгән фикерләр һәм нәтиҗәләр тупланып бирелә. Диплом эшләрендә, диссертацияләрдә, фәнни монографияләрдә бу аеруча күзгә, ташлана. Алар *йомгак* дип атала. Аларда текст мәгълүматы кысылып, тупланып бирелә.

*Проспекция* текстның грамматик категориясе, ул тексттагы контекстуаль мәгълүматның төрле тел чаралары белән белдерелеп, алданиләр булачагына ишарә итә. проспекция *алга*

[104] Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. – Москва: Наука, 1981. – С. 44.

*китеп әйтик, түбәндә (алда) күрсәтелгәнчә, ... башына да китермәгән иде, алга таба күрербез, белгән булса, нихәтле шатланган булыр иде* һ.б. сигналлар белән белдерелә.

Проспекция, хикәяләүдәге бер алым буларак, укучыга сурәтләнә торган вакыйгаларның үзара бәйләнешен куз алдында тотарга мөмкинлек бирә, әсәрнең эчтәлегенә игътибарлырак булырга ярдәм итә: Әмма әле алар үзгә булган (Казан татарларыннан башка: алар хакында, *әйткәнемчә, түбәндә язылыр)* экстерриториаль группалар, ягъни әлеге шул оешулары үзләренең тарихи дәүләтләреннән читтә барган аерым төркемнәр дә бар. *(Р. Фәхретдинов)*

Проспекция фәнни хезмәтләрдә дә була. Автор алда сөйләнәчәк төшенчәләрне куллана да искәрмә бирә: «алар турында без алдарак махсус сөйләрбез».

Проспекциянең үзенчәлекле формаларына кереш, сүз башы, пролог, автордан кебек кисәкләрне кертеп карыйлар.

## Әдәби әсәргә филологик анализ ясау тәртибе

Әдәби текстка филологик анализ ясау аны тарихи, мәдәни, психологик яктан чыгып өйрәнүне күз уңында тота. Текстны филологик яктан өйрәнү системалылыкка һәм индивидуальлеккә юнәлдерелгән. Текстның системалылыгына текстның әдәби юнәлеше, жанры, чор сәясәте, тарихи-мәдәни контексты керсә, индивидуальлелегенә язучының тел үзенчәлеге керә.

I. Гомуми бәяләмә.

1. Әсәрнең авторы турында мәгълүмат.
2. Әсәрдә авторның шәхси үзенчәлекләре чагылышы.
3. Әсәр иҗат ителгән чорга, мәдәни-тарихи контекстка бәя һәм аның текстта чагылу рәвеше.
4. Әсәрнең әдәби юнәлеше һәм әдәби иҗат методлары.
5. Әсәрнең татар әдәбиятында һәм гомумән дөнья әдәбиятында тоткан урыны.

II. Текстка лингвистик анализ ясау үрнәге.

1. Лингвистик комментарияләр, ягъни аңлашылмаган сүзләргә, гыйбарәләргә, ситуацияләргә һ.б. аңлатма бирү.
2. Лингвистик аңлатма бирү.

а) Текстның стиль үзенчәлеге.

б) Текст строфасы:

- җөмләләр арасындагы чылбырлы бәйләнешкә нигезләнгән прозаик строфалар;
- җөмләләр арасындагы параллель бәйләнешкә нигезләнгән прозаик строфалар;
- җөмләләр арасындагы башка төр бәйләнешләргә нигезләнгән прозаик строфалар;
- строфалар арасындагы бәйләнеш алымнары;
- прозаик строфаларның стилистик үзенчәлекләре.

в) Текст стилистикасы.

- Лексик берәмлекләр (күпмәгънәле сүзләрнең, омонимнарның, синонимнарның, паронимнарның, антонимнарның, тарихи һәм архаик сүзләрнең, неологизмнарның, алынмаларның, диалекталь сүзләрнең, терминнарның, һөнәри лексикага караган берәмлекләрнең, жарго һәм арго лексиканың стилистик функцияләре; экспрессив лексиканың һәм фразеологик берәмлекләрнең стилистик кулланылышы);

- сүз ясалышы мөмкинлекләрен стилистик куллану;
- сүз төркемнәрен стилистик куллану;
- стилистик синтаксис (сүз тәртибе, җөмләнең тиңдәш кисәкләре, эндәшләр һәм эндәш сүзләр, кереш һәм керешмәләр, аерымланган хәлләр, кушма җөмлә төрләре, туры һәм кыек сөйләм, цитаталар);
- сурәтләү чаралары (троплар һәм фигуралар);
- текстны барлыкка китерә торган башка берәмлекләр (каламбурлар, палиндромнар, анаграммалар).

г) паратекстуаль чаралар;

д) паралингвистик чаралар.

III. Лингвопоэтик анализ.

1. Әсәрнең темасы (тематикасы).
2. Проблема (проблематика).
3. Идея (идея эчтәлеге).
4. Автор эмоциональлеге тибы (пафос): героик, идиллик, сентименталь, романтик, трагик, комик (юмор, сатира); ироник.
5. Төр һәм жанр үзенчәлеге.
6. Әсәрдәге вакыт һәм пространство.
7. Әдәби әсәрнең вакыйгалар системасын, сюжет һәм хәрәкәт эчтәлеген барлыкка китерә торган элементлар. Конфликт.
8. Композиция. Әдәби текстның төзелеш һәм урнашу үзенчәлеге, сюжет элементларының оешу тәртибе (экспозиция, бәйләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминация, чишелеш). Композиция элементы буларак пейзаж. Пейзаж төрләре. Композиция элементы буларак интерьер. Интерьер төрләре.
9. Шигъри текстларда иҗекләрнең акустик төзелеш үзенчәлекләре: басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең чиратлашуы; шигырь үлчәме, ритм.
10. Әсәрнең образлар системасы. Персонажлар. Персонаж һәм автор (герой һәм автор). Шигъри текстларда лирик Мин. Портрет. Психологизм. Эчке доньяны ачу алымнары: эчке монологлар, кылган гамәлләр, гыйбарәләр, диалоглар, хатлар һ.б. Хикәяләүче образы.
11. Әдәби әсәрнең исеме, поэтикасы.

## Гамәли дәресләрнең тематикасы

***Әдәби әсәрләрдә фонетикага һәм үлчәмгә бәйле экспрессив-эстетик үзенчәлекләрне билгеләү***

1. Әдәби әсәр тудыруда фонетик чаралар.
2. Татар поэзиясендә рифма һәм ритм төрләре.
3. Шигырь үлчәме һәм шагыйрь үзенчәлеге.
4. Сәнгать чарасы буларак интонация һәм поэтик текст мелодикасы.

***Сәнгать әсәре тудыруда лексик-семантик чараларның экспрессив-стилистик роле***

1. Әдәби текстта сүз.
2. Әдәби сөйләмдә образлылык.
3. Күпмәгънәле сүзләрне стилистик куллану үзенчзлеге.
4. Әдәби әсәрләрдә омонимнарның экспрессив кулланылышы.
5. Әдәби сөйләмдә синоним һәм антонимнарның стилистик кулланылышы.
6. Пассив лексик берәмлекләрнең матур әдәбият әсәрләрендә сурәт тудырудагы роле.
7. Матур әдәбият текстларында искергән сүзләрнең стилистик функцияләре.
8. Әдәби сөйләмдә фразеологик берәмлекләрнең стилистик кулланылышы.

***Әдәби әсәр текстында экспрессив-эстетик сурәт тудыруда татар теленең морфологик һәм морфэмик катламы***

1. Морфема мәгънәсенә бәйле стилистик алым.
2. Исем сүз төркеменең сәнгать әсәре тудырудагы роле.
3. Төрле әдәби юнәлешләргә караган әдәби текстларда сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәренең кулланылу үзенчәлекләре.
4. Матур әдәбият текстларында фигыль сүз төркеменең формалары һәм экспрессивлык тудырудагы роле.
5. Матур әдәбият текстларында сан һәм алмашлык сүз төркемнәренең формалары һәм экспрессивлык тудырудагы роле.

6. Әдәби текстны семантик-стилистик яктан бизәүдә ярдәмлек сүз төркемнәренең роле.

***Әдәби әсәр текстында экспрессив-эстетик сурәт тудыруда синтаксик катлам***

1. Матур әдәбият текстларында хикәя, сорау һәм өндәү җөмләләрнең экспрессив бизәк тудырудагы рольләре.
2. Әдәби сөйләмдә бер составлы җөмләләрне стилистик максаттан чыгып куллану.
3. Кушма җөмләләрне әдәби әсәр текстында куллану.
4. Туры сөйләмнең семантик-стилистик функцияләре.
5. Графика чараларына таянып, тамашачы өчен яңа булган эффектка ирешү.
6. Матур әдәбият текстының орфографиясе.
7. Тыныш билгеләренең кулланылыш үзенчәлеге.

***Әдәби әсәрнең сюжеты һәм композициясе***

1. Әдәби әсәрнең композициясе турында төшенчә.
2. Архитектоника, сюжет һәм фабула.
3. Композициянең әсәр сюжетены ачудагы мөмкинлеге.
4. Композициядә әдәби детальләрнең роле.

***Әдәби текстның образлылыгы***

1. Телнең образ-сурәтләү чаралары.
2. Әдәби текстның индивидуаль образ-сурәтләү чаралары.
3. Лингвистик анализда әдәби образның әһәмияте.

***Әдәби әсәрдә автор һәм хикәяләүче образлары***

1. Автор образын филологик якын килеп өйрәнү алымнары.
2. Әдәби әсәрдә хикәяләүче образы.
3. Әдәби әсәрдә автор һәм хикәяләүче образының тәңгәллеге.

***Шигъри текстларның тел үзенчәлеге***

1. Поэтик сүзнең функцияләре һәм семантикасы.
2. Лирик әсәрләр, төрләре һәм үзенчәлекләре.
3. Шигырьләрнең образ-тематик композициясе.
4. Поэтик әсәрләрнең теле.

Поэтик әсәргә укытучы күрсәтмәсе буенча филологик анализ ясау.

### *Проза текстларының тел үзенчәлеге*

1. Эпик әсәрләр, төрләре һәм үзенчәлекләре.
2. Прозада сюжет һәм композиция.
3. Әдәби текстның сюжет-композиция үзенчәлеге.
4. Хикәяләүче образы.
5. Проза әсәрләренең теле.

Проза әсәренә укытучы күрсәтмәсе буенча филологик анализ ясау.

### *Драма текстларының тел үзенчәлеге*

1. Драма әсәрләре, төрләре һәм үзенчәлекләре.
2. Драма әсәрләренең сюжеты, конфликты һәм композициясе.
3. Драма әсәрләренең теле.

## Белемнәрне тикшерү өчен тест

**1. Хәзерге вакытта синтаксик берәмлекләрнең ин зурысы нәрсә?**
а) текст;
ә) җөмлә;
б) сөйләм.

**2. Сөйләм текстта нинди үзенчәлеккә ия?**
а) язма формада күрсәтелә ала;
ә) аралашу функциясен башкара;
б) үзенә хас асыл сыйфатларны күрсәтә ала.

**3. Тел һәм сөйләм арасындагы мөнәсәбәт нәрсәгә бәйле?**
а) сөйләмгә;
ә) телгә;
б) җөмләгә.

**4. Тел ул –**
а) без ишетеп һәм күреп кабул иткән сөйләм агышындагы структур элементлар нигезендә барлыкка килгән чынбарлык.
ә) без ишетеп һәм күреп кабул иткән сөйләм агышындагы структур җөмләләр нигезендә барлыкка килгән абстракция.
б) без ишетеп һәм күреп кабул иткән сөйләм агышындагы структур элементлар нигезендә барлыкка килгән абстракция.

**5. Телнең синтаксик берәмлекләр рәтенә нәрсәләр керә?**
а) сүзтезмә, җөмлә, синтагма, кушма җөмлә, синтаксик бөтен, текст;
ә) сүзтезмә, җөмлә, кушма җөмлә, синтаксик бөтен, текст;
б) сүзтезмә, җөмлә, синтагма, кушма җөмлә, текст.

**6. Җөмлә кисәкләре, сүзтезмә җөмләнең нинди элементларын тәшкил итәләр?**
а) төп;
ә) конструктив;
б) текст барлыкка китерә торган.

**7. Стилистика фәне нәрсә өйрәнә?**
а) әдипләрнең лексик һәм грамматик чаралар ярдәмендә стилистик бизәкләр ясавын өйрәнә.

ә) хәзерге татар әдәби теленең стильләр системасын һәм аларның барлыкка килү тарихын өйрәнә.
б) әдипләрнең синтаксик берәмлекләр ярдәмендә стилистик бизәкләр ясавын өйрәнә.

**8. Текст лингвистикасының өйрәнү объекты нәрсә?**
а) текст барлыкка килү, төзелеше, аны төзүче элементларның эчтәлеге һәм шәкли ягы;
ә) синтаксик бөтен;
б) текст барлыкка килү һәм аның төзелешен.

**9. Текстның табигате нәрсәдән гыйбарәт?**
а) катып калган хәлдә һәм хәрәкәттә була;
ә) катып калган хәлдә яши;
б) хәрәкәттә яши.

**10. Нәрсә ул пресуппозиция?**
а) телдән әйтелгән, әмма тыңлаучы аңында яшәмәгән беренчел мәгълүматлар.
ә) тел чаралары ярдәмендә оешкан хәбәр.
б) телдән әйтелмәгән, әмма тыңлаучы аңында яшәгән беренчел мәгълүматлар.

**11. Микротекстларны һәм макротекстларны нәрсәгә нигезләнеп аералар?**
а) җөмләләрне үзара бәйләүче чараларга;
ә) күләмгә;
б) җөмлә төзелешенә.

**12. Сөйләм телендәге ымнар, интонация, йөз хәрәкәтләре, диалог нәрсә өчен кирәк?**
а) сөйләм барлыкка китерергә ярдәм итәләр;
ә) сөйләүченең фикерен төгәл белдерергә ярдәм итәләр;
б) текст барлыкка китерергә ярдәм итәләр;

**13. Язма телнең төп билгесе нәрсә?**
а) синтаксик бөтен;
ә) диалог;
б) монолог.

**14. Предметлар, күренешләр, билгеләр санап кителә, әммә аларга бәя бирелми. Бу сыйфатлар нинди текстка хас?**

а) хикәяләүче;

ә) тасвирлаучы;

б) фикер йөртүче яки бәяләүче.

**15. Үзгәреп торган процесслар сурәтләнә, заман төсмере һәм урын үзгәреп тора, вакыт белдерүче сүзләр, эмоциональ-экспрессив чаралар кулланыла. Бу сыйфатлар нинди текстка хас?**

а) хикәяләүче;

ә) тасвирлаучы;

б) фикер йөртүче яки бәяләүче.

**16. Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре белдерелә, вакыйгаларда автор мөнәсәбәте чагыла, модаль сүзләр һәм формалар кулланыла.**

а) хикәяләүче;

ә) тасвирлаучы;

б) фикер йөртүче яки бәяләүче.

**17. Текстта нинди мәгълүмат төрләрен күрсәтәләр?**

а) тулы эчтәлекле, концептуаль эчтәлекле, текст артындагы мәгълүмат;

ә) фактик эчтәлекле, концептуаль эчтәлекле, реаль эчтәлек;

б) фактик эчтәлекле, концептуаль эчтәлекле, текст артындагы мәгълүмат;

**18. Нинди эчтәлек укучыны иҗади уйланырга этәрә?**

а) концептуаль эчтәлек;

ә) реаль эчтәлек;

б) текст артындагы мәгълүмат;

**19. Озынлыгы ягыннан текстлар нинди төрләргә бүленәләр?**

а) минималь, максималь;

ә) макро һәм микро;

б) озын һәм кыска.

**20. Текстны керешкә, эпилогка, томга, кисәккә, китапларга, бүлекчәләргә, бүлекләргә, абзацларга, синтаксик бөтеннәргә бүлү нинди бүленеш дип атала?**

а) күләм-прагматик яки текстуаль;

ә) күләм-прагматик яки композицион-график;

б)  композицион-график яки контекстлы-вариатив.

**21. Җөмлә белән белдерелгән хөкемнәр үзара нинди бәйләнештә тора?**

а) тезмә һәм кушма;

ә) тезүле һәм ияртүле;

б) чылбырлы һәм параллель.

**22. Алдагы җөмләнең предикаты яисә субъекты кабатлана яки ачыклана. Алдагы җөмләдәге предикат яңа җөмләдә субъект, ә субъект предикат булып килә. Бу нинди җөмлә тибы?**

а) ияртүле бәйләнеш;

ә) чылбырлы бәйләнеш;

б) параллель бәйләнеш.

**23. Җөмләләрнең кабатланып килгән кисәге бер үк функция үти: һәрбер хөкемдә я субъект, я предикат була. Яңа җөмләдә субъект һәм предикат бөтенләе белән түгел, өлешчә генә кабатланырга мөмкин. Бу нинди җөмлә тибы?**

а) ияртүле бәйләнеш;

ә) чылбырлы бәйләнеш;

б) параллель бәйләнеш.

**24. Җөмләләр арасында нинди бәйләнеш?**

Кара урманнарда ак алмагач,
Алмагачлар саен бал тама.
Ике күзләремдә сиксән керфек,
Керфекләрем саен яшь тама.

а) ияртүле бәйләнеш;

ә) чылбырлы бәйләнеш;

б) параллель бәйләнеш.

**25. Нинди төр когезия?**

Тал иелә, тал иелә,
Нигә иелә икән?
Ах үзәгем, яшь йөрәгем
Нигә өзелә икән?

а) ассоциатив;

ә) образлы;

б) контекстуаль.

**26. Алдагы текстта нинди алым кулланылган?**

Әмма әле алар үзгә булган (Казан татарларыннан башка: алар хакында, әйткәнемчә, түбәндә язылыр) экстерриториаль группалар, ягъни әлеге шул оешулары үзләренең тарихи дәүләтләреннән читтә барган аерым төркемнәр дә бар.

а) кабатлау;
ә) проспекция;
б) ретроспекция.

**27. Нәрсә ул когезия?**

**28. Татар тел белемендә текст төзелешен өйрәнгән галимнәрдән кемнәрне беләсез?**

**29. Текстка хас булган үзенчәлекләрне санап чыгыгыз.**

**30. Функциональ яктан текстларны нинди төрләргә бүләләр?**

## Реферат темалары

1. Дәрдмәнднең шигъри тел үзенчәлекләре.
2. Г.Тукай иҗатында халык иҗатына хас тел үзенчәлекләре.
3. Н.Гыйматдинова повестьләренең лингвистик үзенчәлекләре.
4. Ш.Галиев әсәрләренең лингвистик үзенчәлекләрен өйрәнү.
5. Мөхәммәдьяр әсәрләренең тел үзенчәлекләре.
6. Аманулланың "Әлепле әртисләре" комедиясенә филологик анализ.
7. К.Кәримов хикәяләренә лингвистик анализ (лексик-фразеологик яссылык).
8. М.Акмулланың тел үзенчәлекләре.
9. Г.Исхакыйның "Зөләйха" трагедиясендә жанрга хас тел үзенчәлекләре.
10. Ф.Әмирхан телен өйрәнү.
11. К.Булатова шигырьләренә лингвистик анализ.
12. Һ.Такташ иҗатында поэтик эндәшләр.
13. Г.Бәширов әсәрләрендә персонажлар сөйләме.
14. Г.Ибраһимовның беренче хикәяләрендә романтизмга хас тел-сурәтләү чаралары.
15. Х.Туфан лирикасына лингвистик анализ.
16. Ә.Еники әсәрләрендә уртак сөйләм.
17. Зөлфәт лирикасына филологик анализ.
18. Г.Тукай сатирасына хас тел үзенчәлекләре.

## Зачет өчен якынча сораулык

1. Әдәби текстны өйрәнүнең тарихы.
2. Хәзерге чорда текст теориясен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр.
3. Текст төшенчәсе турында фикерләр төрлелеге.
4. Әдәби текст төрләре.
5. Текст һәм дискурс төшенчәләре арасында нинди бәйләнеш бар? Охшаш һәм аермалы яклары.
6. Текст турында Л.Г. Бабенко өйрәнүләре.
7. Лингвистик анализ. Текст берәмлекләрен аерудагы юнәлешләр.
8. Хәбәрләмә. Хәбәрләмә төрләре.
9. Текст бердәмлекләре.
10. Текстның тышкы структурасы.
11. Синтаксик бөтен.
12. Җөмләләр арасындагы чылбырлы һәм параллель бәйләнеш үзенчәлекләре.
13. Абзац төшенчәсе.
14. Синтаксик бөтен һәм абзац төшенчәләренең аермалы һәм охшаш яклары.
15. Әсәр исемнәре, өйрәнелү тарихы.
16. Башлам һәм бетемнәр. Төрләре.
17. Текстның эчке структурасы.
18. Монологик һәм диалогик сөйләм формалары.
19. Монологик текстның төрләре.
20. Портрет төрләре.
21. Диалог төрләре.
22. Уртак сөйләм үзенчәлекләре, өйрәнелү тарихы.
23. Уртак сөйләмнең лингвистик билгеләре.
24. Уртак сөйләм типлары.
25. Текст эчендәге бәйләнешләр (когезия)
26. Континуум күренеше.
27. Әдәби текстта ретроспекция.
28. Әдәби текстта проспекция.

## Курсны өйрәнүне оештыруга карата методик күрсәтмәләр

***Укытучы өчен методик күрсәтмәләр.*** “Әдәби әсәргә филологик анализ” курсы “Туган (татар) тел һәм әдәбият” белгечлеге буенча өйрәнелә торган лингвистик фәннәрнең рәтенә керә, студентларның татар теле һәм әдәбияты өлкәсендәге белем һәм күнекмәләренә таянып укытуны күздә тота.

Бу курс студентларның тел һәм әдәбият белеме өлкәсендәге төп юнәлеш белән таныштыруны, татар теле һәм әдәбияты өлкәсендәге өйрәнүләрне һәм анализлау методларын өйрәтүне дә максат итеп куя.

Курс дәвамында татар грамматикасы традицияләре саклану белән беррәттән яңа хезмәтләргә дә игътибар итү күз уңында тотыла. Тел белемендә һәм әдәбият белемендә расланмаган яки кабул ителмәгән мәсьәләләргә карата да укытучы үз фикерләрен җиткерә һәм белдерә ала.

Төп нәзари материал лекциядә бирелә. Текстка филологик анализ ясау, специфик һәм уникаль үзенчәлекләре хакында фәнни фикерләр тасвирлана.

Өйрәнелә торган нәзари материалны ныгыту, студентларның лингвистик фикерләү сәләтен һәм тел фактларын анализлау осталыкларын үстерү максатында, семинар дәресләр үткәрелә, сөйләм теленнән, вакытлы матбугат чараларыннан, матур әдәбияттан һ.б. алынган гамәли материал анализлана. Бу очракта мәктәп һәм югары уку йорты программаларының үзенчәлекләре дә игътибарда тотыла.

Курсны өйрәнү барышында студентларның язма һәм сөйләмә рәвештә биремнәр үтәве, докладлар белән чыгышлар ясавы да күздә тотыла. Мөстәкыйль эш буларак, студентларга реферат язу өчен библиографиядә күрсәтелгән кайбер фәнни хезмәтләрне тәкъдим итәргә мөмкин.

Студентларның “Әдәби әсәргә филологик анализ” курсын үзләштерү дәрәҗәсе зачет ярдәмендә ачыклана. Семестр дәвамында семинар һәм гамәли дәресләрдә җаваплар, гомумән, дәрескә йөреш, тест нәтиҗәләре әлеге зачетта билге куйганда исәпкә алынырга тиеш.

***Студентлар өчен методик күрсәтмәләр.*** “Әдәби әсәргә филологик анализ” курсын үзләштерү нәтиҗәсе зачет ярдәмендә бәяләнә.

Мөстәкыйль сәгатьләрдә студентлар:

- темаларга кагылышлы нәзари һәм гамәли материалны үзләштерә, ныгыта;
- тәкъдим ителгән төп һәм өстәмә әдәбиятны укый;
- исемлектә күрсәтелгән һәм башка темаларга материал әзерләп, гамәли дәресләрдә чыгыш ясый;
- күрсәтелгән темаларны мөстәкыйль үзләштерә;
- филологик анализ ясау өчен фактик материал туплый;
- рефератлар һәм язма иҗади эшләр яза.

## Төп әдәбият исемлеге

1.Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. – М.: Комкнига, 2007. – 144 с. - http://www.knigafund.ru
2.Николина Н.А. Филологический анализ текста: Учебное пособие для студентов высших учебных заведений. – М.: Издательский центр «Академия», 2003. – 256 с. - http://www.knigafund.ru
3.Сафиуллина Ф.С. Татар телендә сүз тәртибе. — Казан: Татар кит. нәшр., 1974. – 151 б. (Татарстан ур., 2 – 6 данә)
4.Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар  кит. нәшр., 1993. – 263 б. (Татарстан ур., 2 – 5 данә)

## Өстәмә әдәбият исемлеге

*а) татар телендә:*

5.Абдуллин И.А. Г.Камал драмаларының теле. – Казан: Татар кит.нәшр., 1968. – 200 б.
6.Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред.: А.Х. Әхмәдуллин. – Казан: Татар кит.нәшр., 1990. – 238 б.
7.Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
8.Бәширов Г. Тел турында кайбер фикерләр // Бүген дә, иртәгә дә. – Казан: Татар кит.нәшр., 1974. – Б. 227-236.
9.Баширова И.Б. XIX гасыр ахыры - XX йөз башы татар әдәби теле: исем категорияләре һәм фигыль наклонениеләрендә әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык: Филология фән. докт. ... дис. – Казан: КДУ, 2000. – 471 б.
10. Бәширова И.Б. Сүз белән сурәт ясау (әдәбият укытучысына ярдәмгә). – Казан: Татар кит.нәшр., 1974. – 176 б.
11. Бәширова И.Б. Сәнгатьле чәчмә әсәрләр геле: Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире (VIII – X класслар өчен әдәбияттан кулланма). – Казан: Татар кит.нәшр., – 1979. – 96 б.

12. Газизова Г.Р. Фатих Кәриминең проза әсәрләрендә лексик-семантик һәм стилистик үзенчәлекләр: Филология фәннәре канд. ... дис. – Казан: КДУ нәшр., 2002. – 202 б.
13. Гайфиева Г.Р. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар прозасында хикәя жанры поэтикасы: Филология фәннәре канд. ... дис. – Казан, 2010. – 171 б.
14. Галләмов Ф. Бәйләүче чара буларак кабатлаулар // Мәгариф. – 2001. – № 5. – Б. 100-101.
15. Гарифуллин В.З. Газета текстының төзелеше. – Казан: Татар кит.нәшр., 1995. – 104 б.
16. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традиция һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.
17. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле һәм пунктуациясе. – Казан: Татар кит.нәшр., 1984. – 163 б.
18. Зөлкарнәев Ф. Әверелеш. Шигырь парадокслары. – Казан: Татар кит. нәшр., 1988. – 117 б.
19. Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар. – Казан: КДУ нәшр., 1976. – 167 б.
20. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика. – Казан: КДУ нәшр., 1990. – 156 б.
21. Кузьмина Х.Х. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында тел-стиль үзенчәлекләре: (Махсус курс программасы). – Казан: КДУ нәшр., 2001. – 24 б.
22. Кузьмина Х.Х. Хәзерге татар прозасының теле // Милли мәдәният. – № 11. – 2000. – Б. 44-47.
23. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.
24. Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре. – Казан: Татар кит. нәшр., 1956. – 176 б.
25. Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби телендә туры, кыек һәм уртак сөйләмнәр: Филология фән. канд... дис. – Казан, 1953. – 341 б.
26. Курбатов Х.Р. Хәзерге татар теленең стилистик системасы. – Казан: Татар кит. нәшр., 1971. – 248 б.
27. Лерон Л. Хәлең ничек, татар прозасы? // Казан утлары. – 2007. – № 6. – Б. 96-102.

28. Мөхәмәдиев М.Г. Шәриф Камал прозасының теле. – Казан: Татар кит.нәшр., 1991. – 136 б.
29. Низамов И.М. Уем тел очында... (Сөйләм һәм массакүләм аралашу) // Татар сөйләменең нигезләре. Беренче кисәк. – Казан: Татар кит. нәшр., 1995. – 287 б.
30. Поварисов С.Ш. Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү. – Казан: Татар кит. нәшр., 1978. – 217 б.
31. Сафина Н. Ил турында “Ил” китабы // Казан утлары. – 2000. – №12. – Б. 140-144.
32. Сафиуллина Ф.С. Сүз иясе белән йөри. — Казан: Татар кит. нәшр., 1985. – 136 б.
33. Сафиуллина Ф.С. Тел дигән дәрья бар... — Казан: Татар кит. нәшр., 1979. – 136 б.
34. Татар грамматикасы. – Том III. – М.: “ИНСАН”, Казан: “ФИКЕР”, 1999. – 512 б.
35. Хаков В.Х. Мәктәптә татар язучысының тел үзенчәлекләрен өйрәнү. – Казан: Татар кит.нәшр., 1984. – 145 б.
36. Хаков В.Х. Татар әдәби стиле (стилистика). – Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. – 304 б.
37. Хаков В.Х. Татар милли әдәби теле һәм аның стильләре үсеше. XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башы: Филология фән. докт. ... дис. – Алма-Ата, 1971. – 176 б.
38. Хаков В.Х. Татар теле стилистикасына кереш. – Казан: Татар кит. нәшр., 1963. – 164 б.
39. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан) / В.Х. Хаков. – Казан: Татар кит. нәшр., 2003. – 295 б.
40. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Раннур, 2002. – 352 б.
41. Шакирова Г.М. Гаяз Исхакый әсәрләренең текст буларак оешуы: фил. ф. канд. ... диссертациясе. – Казан, 2009. – 197 б.

*ә) рус телендә:*

1. Абдуллина А.Ш. Поэтика современной башкирской прозы: автореферат дис. ... док. фил. н. – М.: МПГУ, 2009. – 42 с.
2. Арутюнова Н.Д. Человеческий фактор в языке. Коммуникация, модальность, дейксис. — М.: Наука, 1992. – 281 с.

3. Бабенко Л.Г. Лингвистический анализ текста. – Екатеринбург: Изд-во Урал. ун-та, 2000. – 534 с.
4. Баранов А.Г. Функионально-прагматическая концепция текста. – Ростов-на-Дону: Изд-во Ростовского университета, 1993. – 182 с.
5. Беличенко Е.Е. Несобственно-прямая речь в языке художественной литературы (на материале анималистической прозы): автореферат дис. ... канд. филол. н. – СПб: Изд-во СПбГУ, 2006. – 23 с.
6. Болотнова Н.С. Филологический анализ текста: учеб. пособие. – М.: Флинта: Наука, 2009. – 520 с.
7. Брудный А.А. Психологическая герменевтика. – М.: Лабиринт, 1998. –336 с.
8. Валгина Н.С. Теория текста: учебное пособие. – М.: Логос, 2004. – 280 с.
9. Виноградов В.В. О теории художественной речи. – М.: «Высшая школа». 1971. – 181 с.
10. Виноградов В.В. Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика. – М.: Изд-во АН СССР. – 1973. – 255 с.
11. Винокурова И.Ж. Языковой механизм связности зачина и концовки в тексте короткого рассказа // Вестник ЯГУ. Том 4, № 1. – Якутск: Изд-во ЯГУ, 2007. – С. 79-85.
12. Ворожбитова А.А. Теория текста: Антропоцентрическое направление: учеб. пособие. – М.: Высшая школа, 2005. – 367 с.
13. Гайфиева Г.Р. Основные этапы становления жанра рассказа в татарской литературе // Вестник ЧГПУ. – №4. – 2010. – С. 223-229.
14. Есин А.Б. Принципы и приемы анализа литературного произведения / А.Б. Есин. – М.: Флинта. Наука, 1999. – 246 с.
15. Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка. – Казань: Изд-во КГУ, 1963. – 464 с.
16. Закономерности развития и взаимодействия национальных яыков и литератур (Текст. Коммуникация. Перевод): тезисы науч.-практич. конференции (27-30 сент. 1989 г.). Ч.1-2. – К.: Изд-во КГУ, 1989. – 168 с.
17. Ибатуллина Д.Э. Поэтика прозы Амирхана Еники: автореферат дис. ... канд. филол. наук. – Казань: Б.И., 1993. – 21 с.

18. Иванчикова Е.А. Синтаксис художественной прозы Достоевского. – М.: Наука, 1980. – 287 с.
19. Искужина Ф.С. Текст и средства его организации в современном башкирском языке (на материале произведений художественной литературы): автореферат дис. ... канд. филол. наук / Ф.С. Искужина. – Уфа, 2000. – 24 с.
20. Касавин И.Т. Текст. Дискурс. Контекст. Введение в социальную эпистемиологию языка. – М.: «Канон+» РООИ «Реабилитация», 2008. – 544 с.
21. Кожевникова Н.А. Типы повествования в русской литературе XIX -XX вв. – М.: Наука, 1994. – 335 с.
22. Корниенко А.А. Теория текста малых художественных форм. Французская новелла второй половины XX века: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – М.: МГУ им. М.В.Ломоносова, 2001. – 59 с.
23. Кубрякова Е.С., Александрова О.В. Виды пространств текста и дискурса // Категоризация мира: пространство и время. Материалы научной конференции. – М., 1997. – С. 144-238.
24. Кузнецов А.М. Коммуникативное воздействие литературно-художественного текста // Речевое воздействие в сфере массовой коммуникации. – М.: Наука, 1990. – С. 108-117.
25. Кузьмина Х.Х. Принципы анализа языка художественных произведений в татарском языкознании // Ученые записки КГУ. Том 150, кн. 8. – К.: Изд-во КГУ, 2008. – С. 116-122.
26. Купина Н.А. Филологический анализ художественного текста: Практикум / Н.А.Купина, Н.А.Николина. – М.: Флинта: Наука.–2003.– 408 с.
27. Лингвистика и филологическая герменевтика: Сборник научных трудов. – Тверь: Изд-во ТвГУ, 2003. – 134 с.
28. Литературный текст: проблемы и методы исследования // Тверской государственный университет: Отв. ред. И.В.Фоменко. – Тверь: Изд-во ТвГУ, 1994. – 178 с.
29. Лотман М.Ю. Анализ поэтического текста. – Л.: Просвещение, 1972. – 32 с.
30. Москальская О.И. Грамматика текста. – М.: Выс. школа, 1981. –183 с.

31. Набиуллина Г.М. Особенности структурной поэтики башкирской прозы 70-90-х годов: автореферат дис. ... канд. филол. наук. – Уфа, 2001. – 23 с.
32. Новиков Л.А. Художественный текст и его анализ. – М.: Наука, 1988. – 253 с.
33. Одинцов В.В. О языке художественной прозы: повествование и диалог. – М.: Наука. – 1973. – 104 с.
34. Одинцов В.В. Стилистика текста. – М.: Наука. – 1980. – 264 с.
35. Почепцов Г.Г. Прагматика текста // Коммуникативно-прагматические и семантические функции речевых единиц: Межвуз. тематич. сборник. – Калинин: КГУ, 1980. – С. 5-10.
36. Поэтика современной татарской прозы: Межвузовский сборник научных трудов. – Казань: КГПИ, 1984. – 110 с.
37. Реферовская Е.А. Лингвистические исследования структуры текста. – Л.: Наука, Ленинградское отделение, 1983. – 216 с.
38. Сафиуллина Ф.С. Порядок слов в современном татарском литературном языке: автореферат дис. ... канд. филол. наук. – К.: Изд-во КГУ, 1965. – 21 с.
39. Сафиуллина Ф.С. Порядок слов в современном татарском литературном языке: диссертация ... канд. филол. наук. – К.: Изд-во КГУ, 1965. – 305 с.
40. Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского литературного языка (XX век): дисс. в виде науч. докл... д-ра филол. наук. – К.: Изд-во КГУ, 2000. – 116 с.
41. Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период: (Простое предложение). – Казань: Изд-во КГУ, 1990. – 228 с.
42. Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи. – Казань: Изд-во КГУ, 1978. – 253 с.
43. Серебрякова С.Г. Функционально-стилистические особенности С.Г. Серебрякова. – СПб: СПбГУ, 2007. – 18 с.
44. Солганик Г.Я. Стилистика текста. — М.: Флинта, Наука, 1997. – 256 с.
45. Теория текста: учеб. пособие / Ю.Н. Земская, И.Ю. Качесова, Л.М. Комиссарова, Н.В. Панченко, А.А Чувакин. – М.:Флинта, Наука.– 2010. – 132 с.

46. Тер-Минасова С.Г. Язык и межкультурная коммуникация. – М.: Слово, 2000. – 262 с.
47. Тураева З.Я. Лингвистика текста (Текст: структура и семантика). – М.: Просвящение, 1986. – 241 с.
48. Филиппов К.А. Лингвистика текста: Курс лекций. – СПб.: Изд-во СПб. унив-та, 2003. – 336 с.
49. Хатипов Ф.М. Теория литературы. – К.: Магариф, 2000. – 351 с.
50. Хисамова Г.Г. Язык современной художественной прозы: диалог в рассказах В. М. Шукшина. – Уфа: БГУ, 2000. – 78 с.
51. Художественный текст в современной лингвистической парадигме: учебно-методич. пособие для вузов. – Воронеж: Изд-во унив-та, 2007. – 50 с.
52. Чернявская В.Е. Лингвистика текста: поликодовость, интертекстуальность, интердискурсивность. Учеб.пособие. – М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2009. – 248 с.
53. Шаехов М.Р. Структура текста современных татарских рассказов: автореферат дис. ... канд. филол. наук: 10.02.02.- Казань, 2012.- 22 с.
54. Шакирова Г.М. Синтаксическая организация текста художественной прозы Гаяза Исхаки: автореферат дис. ... канд. филол. наук. – К.: Изд-во КГУ, 2009. – 27 с.
55. Шанский М.Н. Лингвистический анализ художественного текста. - М.: Просвещение, 1990. – 268 с.
56. Язык и композиция художественного текста: Межвузовский сборник научный трудов. – М.: МГПИ, 1986. – 100 с.
57. Язык и речь как объекты комплексного филологического исследования: Межвузовский тематический сборник. – Калинин: Изд-во КГУ, 1980. – 156 с.

Издательство «Отечество»
420111, г. Казань, ул. Лево - Булачная, 24

Подписано в печать 06.02.2013. Форм. бум. 60х84 1/16.
Печ. л. 4,9. Тираж 100. Заказ № 2002/4.
Отпечатано с готового оригинал – макета
в типографии «Вестфалика» (ИП Колесов В.Н.)
420111, г. Казань, ул. Московская, 22. Тел.: 292-98-92